Фәнис НУРЕТДИНОВ

ШАЯН ХӘЛЛӘР

Фәнис НУРЕТДИНОВ

Шаян хәлләр

Чаллы, 2006

Фәнис Бари улы Нуретдинов.
Шаян хәлләр: Мәзәкләр. — Чаллы, — 2006 — 64 бит.

Елмаешып теләк теләшик

Ничә гасыр инде, эт — кешенең
Ышанычлы дусты, юлдашы.
Эт елының тәүге минутларын
Саный сәгать... Яңа ел башы.

Бу ел бәхет-шатлык алып килсен,
Якты өметләрне акласын.
Эт дустыбыз кайгыларны кусын,
Безнең тынычлыкны сакласын.

Нинди авыр заманнарда түздек,
Безгә дә бер бәйрәм килер, дип.
Уттан алып, суга салсаң гына
Чынығулар ала тимер, дип.

Сез дә безне, без дә сезне котлап
Елмаешып теләк теләшик.
Киләчәктә матур булыр тормыш,
Күңелләргә өмет өләшик.

Без керәбез бүген Эт елына,
Бәйрәм итик әле гөрләшеп.
Мәзәк сөйләп, матур тостлар әйтеп,
Бер утырыйк әле серләшеп.

КЕРЕШ СҮЗ

Фәнис Бари улы Нуретдинов 1952 нче елда Чирмешән районының Иске Кади авылында туып үсә.

Белеме — Минзәлә совхоз-техникумы. Берара Фәнис Минзәлә район газетасында штаттан тыш хәбәрче вазифасын башкара. Шул вакыттан үзе дә сизмичә язу эшенә тартыла.

Ул тормышыбызда очраган мәзәк хәлләр, көлкеле күренешләрдән үзенчә мәгънә таба. Аларны үзенең куен дәфтәренә бөртекләп язып, теркәп бара. Әлеге мәзәкләрдә татар халкына хас тапкырлык, зирәклек, киң күңеллелек, шаянлык, эчкерсезлек кебек сыйфатлар тасвирлана. Фәниснең инде өч китабы дөнья күргән.

Мәзәкләре республикабыз газеталарында, бигрәк тә "Ватаным Татарстан", "Татарстан яшьләре", "Шәһри Чаллы", "Таң йолдызы" газеталарында даими басылып килә.

Ул татар халкының тирән акылына, чиксез сабырлыгына, зирәклегенә, тапкырлыгына соклана.

Үзенең авылын ярата. Аның гүзәл табигате, кунакчыл, ярдәмчел, игелекле, эчкерсез, матур күңелле кешеләре, аларның сокландыргыч хезмәтләре турында уйлана.

Без Фәнискә яңадан-яңа иҗади уңышлар, бәхетле язмыш телибез.

Фәйрүзә Хәйдәрова.

Беренче бүлек

"АЯКЛАР ЙОКЛЫЙ АЛМЫЙ"

Бәләкәй Алмаз әбисе белән йокларга яткан да, йоклый алмыйча, боргаланып, аяклары белән тыпырчынып ята икән.

— Нигә йокламыйсың, улым? — дип сораган әбисе.

— Бик рәхәтләнеп йоклар идем дә, аяклар йокыга китмичә, үзем йоклый алмыйм шул, — дип җаваплаган Алмаз.

"ТАГЫН БЕР ӘЙЛӘНИК ӘЛЕ"

Хәлим сеңлесе белән шәһәргә абыйларына кунакка килә. Килсәләр, өйдә беркем дә юк. Бераз урамда йөреп керергә булалар. Йөри торгач, сеңлесе Галиянең тамагы ача. Ашханә яныннан узганда Хәлимгә:

— Абый, әйдә тагын бер генә әйләник әле шул төштән, бигрәкләр дә тәмле исләр килә бит, — дип, төкереген йотып куйган.

"ТАГЫН ПЕШЕР ӘЛЕ"

Хәлимә әби, авыр заманнарны исенә төшереп, оныкларына черек бәрәңге кәлҗемәсе турында сөйли икән. Бу сүзләрне еш ишетеп туйган җиде яшьлек Марат:

— И-и, әбекәем, бигрәкләр дә тәмле булган ул кәлҗемәң, әүзең бер дә пешермисең шул тәмле әйбереңне, гел сөйләп кенә кызыктырасың, — дип, телләрен ялап куйган.

"ПОДРУГАСЫ МЫЕКЛЫ ИДЕ"

Өч яшьлек Гөлсинәнең әтисе командировкадан кайтып төшә.

— Йә, кызым, мин өйдә булмаганда кемнәр килде безгә?

— Әниемнең подружкасыннан башка беркем дә килмәде.

— Кайсы подругасы, теге пионинода уйный торган озын бармаклы Галия апаңмы?

— Юк, ул подругасы мыеклы иде, әти, — дип куйган бәләкәй Гөлсинә.

"САТЫП АЛГАН БИШЛЕҢ ТҮГЕЛ"

Алмаз мәктәптән иселе алып кайткан саен, ана әнисе Миңсылу ападан бик каты эләгә. Бу хәлгә түземлеге беткән Зәйтүнә әби Алмазның укытучысы Хәдичәнең өенә бара: "Балакайгынам, Алланың берлеге хакына, бишлеңне куй! Сатып алган бишлең түгел ләбаса, юкса, малайны киленнән кыйнатып үтертәсең бит!"

"УЛ РОГАТКА ТҮГЕЛ БИТ"

Элегрәк мәктәпләрдә рогаткалардан атып шаяру бар иде. Бервакыт Рамил шулай рогаткадан ата. Укытучы апа аның кесәсенә рогаткасын алам дип кулын тыккач, малай чәрелдәп җибәрә:

— Апакайгынам! Ул рогатка түгел бит! Мин башка шаярмам, — дип ялвара.

Тәнәфестә генә эш нидә булганы ачыклана. Баксаң, Рамилнең кесәсе тишек булган икән.

"АЯГЫҢ БЕЛӘН ЯЗСАҢ ДА"

Алтмышынчы еллар башында татар теленнән матур язу дәресендә була бу хәл. Укытучы бер укучыны ачуланып битәрли башлый:

— Син, Хикмәтуллин, аягың белән язсаң да, моннан матуррак язар идең.

Күпмедер вакыт үткәч, класстагы укучыларның шаркылдап көлүләренә укытучы күтәрелеп карый. Хикмәтуллин, аягының бармакларына ручкасын кыстырып, дәфтәренә хәрефләр төшереп утыра икән. Бу хәлне күреп, укытучы үзе дә көлеп җибәргән.

"УРЫСЧАСЫ "ЧӘНЧҮШКӘ"

Хәлимә әбинең оныгы Алмаз дәрес әзерләп утыра икән:

— Әби, әби, ефрейтор сүзенең урысчасы ничек була? — дигән.

Хәлимә әби шук оныгы тагын шаяртадыр дип:

— Әнә, эшең булмаса, урамга чык та кәкерәеп тор, — дигән.

— Юк, юк, әбекәй, мин бит шаяртмыйм. Менә монда тагы керпенең урысчасы ничек, дип сораганнар.

Хәлимә әби, урысчаны яхшы сукалаган кеше сыман:

— Аны кем белми!? Ул бит чәнчүшкә була, — дип куйган.

"АХБАХ БУЛА УЛ"

Сәлих абый, авырып алганнан соң, яңадан мәктәпкә китә. Бу вакытта математикадан х+у өйрәнәләр икән. Җитмәсә, яңа укытучы килгән вакыт. Укытучы апа тактага ах+вх дип яза да, журналда билгеләре булмау сәбәпле, Сәлих абыйны такта янына чакырып:

— Бу нәрсә була? — дип сорый.

Сәлих абый элек өйрәнгән, үзе белгән хәрефләрне бергә куша да: "Ах+бах, була ул ахбах", — дип куя.

"ЯТКАН ҖИРЕҢДӘ ЯТ ТА ЯТ!"

Абыйлы-энеле өченче һәм бишенче сыйныфта укучы Хәлим белән Мансур грипп белән авырып киткәннәр. Бер атнадан соң терелә башлаган Хәлим абыйсына:

— Җитте, болай яту туйдыра башлады. Әллә, булмаса, торабызмы? — дигән.

— Бу рәхәттән туйдыңмы әллә? Тәмле итеп ашаталар, мәктәпкә барасы юк, яткан җиреңдә ят та ят!

ПИВО ШИКЕЛЛЕ

Ике яшьлек Рамил садикта ишек алдында уйнап кергәч, кече йомышын йомышлап горшокта утыра. Эшен бетереп торып баскач, шунда торган нянька апасына:

— Карагыз әле, нинди күбекле пиво булды, — дип куйган.

"ҖИВИ ХОРОШО"

Рамил хатыны белән дүрт яшьлек кызын ташлап китә. Баласына берничек тә ярдәм иткәне булмый. Бер көнне өч яшьтә үк хәреф танырга өйрәнгән кызы әтисенә хат яза. "Папа! Живи хорошо, ни в чем себе не отказывай", дип конвертка ун сум акча да сала.

"СИНЕ АННАН АТАРМЫН"

Чаллы татар драма театры артистлары Аксубай якларында "Аты барның дәрте бар" спектакле белән йөргән вакытта була бу хәл. Тәнәфестән соң, барлык бала-чага да буфеттан "чипсы" алып кереп, шуны кетер-кетер ашап, спектакльне дәвам итәргә комачаулый.

Кулына мылтык тоткан Булат Сәлахов Инсафны атарга тиеш була. Залдагы кетердәүле хәлне күреп, Булат әйтеп куя: "Инсаф, син бераз сабыр ит инде. Башта мин бу залда чипсы ашап утыручыларны атам".

Зал шым була. Спектакль көчле алкышлар астында тәмамлана.

"МЕНӘ ШУЛ БУЛА"

Мөкаттәрә апа 70 нче еллар башында Чаллы жирлегендә агроном булып эшләгән чорда була бу хәл. Райком секретаре, тырыш, уңган кешегә хөрмәт йөзеннән, бишекле мотоцикл бирергә була.

— Үз җаегызга, кая кирәк, шунда рәхәтләнеп йөрегез!

Олы яшьтәге Мөкаттәрә апа, матайны кирәксенмичә:

— Юк, кирәкми, рәхмәт инде зурлавыгыз өчен! Минем анда утырып йөрергә исәнлегем юк, — дигән. Райком секретаре аптырашта калып:

— Бу ни була инде! Күрсәт яхшылык, көт яманлык, — дигәч, Мөкаттәрә апа уенын-чынын бергә кушып:

— Сзади геморрой, спереди фибриома, менә шул була инде, — дип җаваплаганнан соң аңа ГАЗ-69 машинасы бирергә булалар.

"ГИТЛЕР ТАТАР БУЛГАН..."

Авыл клубында сугыш турында татарчалаштырылган кино була. Радиодан "Бик шәп кино була", дигән хәбәр булгач, яше-карты клубка җыела.

Икенче көнне авыл агайлары капка төбендә шул фильм турында гәпләшеп утыралар икән. Гомере буе авылдан читкә чыкмаган, сугыш күрмәгән, яшьтән үк гарип калган, чулак Гариф бабай да сүзгә кушыла:

— Карале, мәйтәм, ул Гитлер дигәннәре татар булган икән бит...

"ТРАКТОРДА АШАМЫЙЛАР"

Мулланур, Чаллы шәһәренә килгәч, Центральная урамындагы "Трактиръ" кабымханәсенә кереп, ашап чыгасы итә. Шунда кодасы Фәнилне очрата. Авылга кайтып, әнисенә кодасының кайнар сәламнәрен тапшыргач, төшке ашны "Трактиръ"да ашаганлыкларын әйтә.

— Китсәнә, юкны сөйләп торма?! — ди "Трактиръ" сүзен аңламаган Фәния апа. — Фәнилнең нинди тракторы булсын да, кем инде тракторда ашап йөри? Син салып кайткансың ахрысы, малай актыгы!

"ЧУРТЫМ БУЛСА ДА, КАЙНАР БУЛСЫН"

Зөфәрнең авылда мәктәп тәмамлап шәһәргә килгән вакыты. Эшкә урнашып йөргән чакта ашханәдә тамак ялгап чыгарга була бу. Тәлинкәләргә салынган ризыкларны ала да, өстәл артына утырып, бер кашык салкын аш кабып, аптырашта кала.

— Кара, нинди сап-салкын аш ашаталар, — дип, тәлинкәсен тотып, пешекчеләр янына китә.

— Сез нигә миңа салкын аш бирдегез? — дигәч, пешекче кыз:

— Бу бит окрошка! Окрошка салкын була, — дип аңлата.

Авыл җирендә гомер ишетмәгән бу сүзгә каршы Зөфәр:

— Миңа димәгәе, окрушка түгел, чуртым булсын, тик ашыгыз кайнар булсын, — дип тузыныпмы тузына икән.

"ЖИТЬ ИЛИ НЕ ЖИТЬ"

Элегрәк заманнарда кыйммәтле һәм затлы саналган "Быть может" дигән хушбуйны Мөкаттәрә апа, килене сорагач, Яңа елга бүләккә алып кайтырга була. Кибеткә барганда юл буе, онытмаска теләп "Быть может, быть может", — дип кабатлап бара икән.

Хәерчегә җил каршы, дигәндәй, кибеттә бер дусты килеп исәнләшкәч, хушбуйның исемен оныта бит.

— Нәрсә карыйсың, Мөкаттәрә апа? — дип сорый аннан таныш сатучы.

— "Жить или не жить" дигән духи кирәк иде, шуны эзлим! — дип җаваплый Мөкаттәрә апа.

"СВЕЖИЙ ТҮГЕЛ ИКӘНСЕҢ"

Хәмдебану апаның бераз гына акылга җиңелрәк кызы эшкә урнашырга комиссия узып йөри икән. Бер-ике көн тикшеренгәннән соң иптәш кызлары аңардан:

— Ничек соң комиссияң? Анализларың әйбәтме? — дип сораганнар.

— Әй лә, бер дә юкка борчылып йөрмә, барыбер свежий түгел икәнсең, дип, әйтеп җибәрделәр, — дигән.

"СИН МОРЖАДАН, МИН ТӘРӘЗӘДӘН"

Кыш көне Габтерәүф абый белән Сәмигулла абый фермада терлекчеләр өендә утырганда парторг Галимҗан абый килеп керә. (Өчесе дә сугыш ветераннары, урыннары җәннәттә булсын.)

— Карагыз әле, егетләр! Бөтен дөньягызны кар баскан, ишегегезне дә ачарлык түгел, ул-бу була калса, ничек чыгарсыз соң?.

— Габтерәүф — моржадан, ә мин — тәрәзәдән, — дип җавап бирә җор телле Сәмигулла абый.

Габтерәүф абзыйның хәтере кала:

— Нишләп соң әле мин моржадан чыгарга тиеш, ә син тәрәзәдән?

— Чөнки синең кушаматың Убыр, моржадан бик ансат йөрисең, ә минеке Тавык — очам да чыгып китәм тәрәзәдән, — дип шаркылдаган Сәмигулла абзый.

"САНДУГАЧ БАЛАЛАРЫ ШИКЕЛЛЕ"

Биткә ямьсез, шадра битле Минәхмәт абый, сугыш ветераны, кысык күзле, чалыш авызлы Габтерәүф абзый фермада эшләделәр. Бервакытны болар, бераз салып алгач, талашып китәләр. Син ямьсез дә, мин матур, дип озак кына тартышканнан соң, кайсысының ямьсез икәнен дәлилләү өчен, тапкыр сүзле Сәмигулла абзыйдан сорарга булалар. Сәмигулла абзый тегеләрнең берсен дә кимсетмәскә тырышып:

— Икегез дә бик матурлар, йоны чыкмаган сандугач балалары шикелле, — дигәч кенә тегеләр елмаеп җибәргәннәр.

"КАЙСЫ ДУҢГЫЗЫ КАБЫЗГАН?"

Рифкать абый өенә комбайн белән кайтып, тыкрыкта тукталган да, бөртек бушата торган шнекны бакча ягына борып куя. Шнек бодай бушаткан арада, үзе чәй эчәргә кереп китә. Бәхетсезлеккә каршы, үтеп барган колхоз рәисе, бу күренешне күреп, хәйран кала. Кызган баштан Рифкатьне өеннән өстерәп чыгарып, аты-юлы белән сүгәргә тотына.

Рифкать абый, берни дә булмагандай, авызындагы ипи кисәген чәйни-чәйни:

— Кара әле, карале, малакайгынам! Кайсы дуңгызы кабызган икән бу комбайнны? — дип кычкыра-кычкыра, тыкрыкта уйнап йөргән малайларны куып китә.

"БЕРАЗ ЮАРГА КИРӘК"

Гата абзый кибет янында тимерче Минәхмәт абый белән очрашкач:

— Ай-яй, искитмәле булган бит муенның! — дигән.

Минәхмәт абый бу сүзләрне мактау мәгънәсендә аңлап:

— Тәрбия яхшы бит, менә хәзер йөз иллене җибәрәм дә, кайткач ике кукәй эчәм, — дип куйган.

— Муеның калын дип әйтүем түгел, бигрәк каткан бит, бераз булса да юарга кирәк иде, — дип сүзен ярып салган Гата бабай.

"ӘПӘЙ БЕЛӘН ГЕНӘ АШЫЙМ"

Элегрәк заманда авылда зур бәдәнле, бер утыруда бер чуен бәрәңге ашап бетерә торган Шәйхи бабай бар иде. Авылдагы иң авыр эшләргә аны чакыра иделәр.

Бервакыт Фатыйх мулла моны баз казырга яллый. Хатынына кечкенә ашка коймак пешерергә куша. Эштән соң хуҗабикә өстәлгә хуш исле майлы коймак чыгарып куя. Коймакның майда чыпырдап торганына исе китеп, Шәйхи бабай ашамыйча утыра икән.

— Нигә ашамыйсың? — дип сорый мулла бабай.

— Миңа баштан әпәй бирегез, коймакны әпәй өстенә генә куеп ашыйм, шунсыз мине туйдыра алмассыз, — ди.

— Оялып утырма, коймак җитәрлек, туйганчы аша, — дигәч кенә Шәйхи бабай коймакны сыптырып бетерә:

— Элегә чаклы мондый тәмле ризыктан тамагым туйганы юк иде, сез мине сихерләдегез, ахрысы, — дип рәхмәтен әйтеп чыгып китә.

"ДИЕТАГА КҮЧТЕ"

Авылга кунакка кайткач, Хәлим дусты Әмингә:

— Нәрсә күреп симерәсең син! Тормыш мәшәкатьләрең җиңеләеп киткән ахрысы? — ди икән.

Шунда Әминнең өстәл әзерләп йөргән хатыны Зөбәйдә :

— Әмин бит хәзер диетага күчте, төнлә дә торып ашый башлады, — дип елмайган.

"ӘЛЛӘ ЧЫНЛАП БУАЗ БУЛГАНМЫ?"

Әхәт абзый аучы Хәсәнҗан бабайларга хәл белергә бара. Хәсәнҗан бабай аудан сусар тотып кайтып, шуның тиресен тунап ята икән. Кунак килеп кергәч, офтанып:

— Малакайгынам, буаз булган бит, балалары пәрәме жалко булды, — дигән.

Шуннан соң болар чәй эчәргә өйгә кереп китәләр. Үз күзләре белән күреп торса да, Әхәт абзый сүз юктан, сүз ясап:

— Карале, Хәсәнҗан, әллә сусар чынлап та буаз булганмы? — дип төпченә икән.

"БӨРТЕК"

Гамир бабай иптәшләре белән Мәскәү шәһәренә барганда Казан вокзалына килеп төшә. Элек читтә йөрмәгәнгә күрәдер инде, вокзал идәннәренең чиста һәм тигез булуына исе китеп:

— Вәт менә монда тары суктырсаң, бер югалтусыз бөртегенә кадәр җыеп алыр идең, — дип куйган. Менә шуннан соң инде Гамир бабайга мәңгелеккә "бөртек" кушаматы тагылып кала.

"РӘСӘЙДӘ КӘҖӘ САВЫП"

Алтмышынчы еллар башында була бу хәл. Район башкарма комитетында авыл советы рәисләре сөт тапшыру планын үтәү буенча хисап тоталар. Төп сүз авыл хезмәтчәннәреннән күбрәк сөт тапшырту турында.

— Татарстан буенча безнең район сөт тапшыруда иң арттагы рәтләрдә сөйрәлә, әгәр дә авыл советлары ярдәме белән халыктан дәүләткә сөт тапшыруны арттыра алсак, бәлки үзгәрешләр булыр иде, — дип ассызыклый исполком җитәкчесе.

— Безнең "Россия"дә күпчелек кәҗә, кәҗә сөте тапшырып кына дәүләт планын үтәп булмас шул, — дип әйтеп сала "Россия" хуҗалыгына кергән авыл советы рәисе.

Исполком җитәкчесе, шаярта торган гадәте буенча:

— Җәмәгать, бөтен Рәсәйдә кәҗә савып кына план үтәп булмас шул инде, — дип көлгән.

"ПИВО БУЛСА, ЭЧӘР ИДЕМ"

Хәлим Казанда студент булып укып йөргәндә, тәки шәһәрчә сөйләшергә өйрәнеп китә бит. Авылга кунакка кайткач, дусты Сәлим янына, ике шешә сыра тотып, хәл белергә бара.

— Нәрсә, брат, сыра эчәбезме? — диеп, Казанча әйтеп сала. Авылда Сәлимнең сыра сүзе колагына кереп чыкмаганга күрәдер инде:

— Юк, брат, мин сыра эчмим, пиво булса, эчәр идем, — дип иренен ялап куя.

"БЕР ПАР РУКАВИЦА"

Миннәхмәт абый, бик зур бәдәнле таза кеше иде. Бөек Ватан сугышында кул пулеметы белән фашист "мессерын" бәреп төшергән ул. Авыл халкының күңеленә кереп калган каты сүзле бик кызык кына кеше иде.

Әнисе моны бервакыт битәрли икән:

— Син сарык тиресен тире җыючыга тапшырасың да, акчасын эчеп бетерәсең, әнә Бөке Зәкие үзенә менә дигән тун тектергән.

— Әй, энкәй! Бәләкәй бәдәнле Бөке Зәки туныннан миңа бер пар рукавица гына чыга бит, — дип җаваплаган Миннәхмәт абый.

"ЧЕБУРАШКА"

Миннәхмәт абый, үзенә кирәкле кешеләрне бер бригадага туплап, шабашкага китеп бара. Араларында кечкенә генә буйлы, сөйләшкән чакта кысылып, эшне бозып куючы Минсалих абый да бар икән.

Икенче көнне эш башларга килешү төзергә киткәндә Минәхмәт абый иптәшләренә:

— Берүк бу "чебурашка"ны җибәрә күрмәгез, үзе кечкенә булса да, кисап буйлы теле аркасында бөтен эшне болгатачак, — дип кисәткән.

"НУ АШАТКАН ШИКӘРНЕ"

Умарта тотучы Мәлик карт күрше авылга кунакка бара. Чәй эчкәндә бабайны бал белән сыйлыйлар. Балны капкан саен үз-үзенә сөйләнеп:

— Ну ашатып караганнар шикәрне, бер дә бал тәме юк, — дигән картыбыз.

— Үз балыңны капкандай итеп сыйлан, Мәлик абзый, — дип кыстый икән хуҗа хатын, ә чынлыкта бал Мәлик карттан алынган була.

"КӘГАЗЕ БИК МАТУР"

Кәлимулла бабай балның килосын биш сумга сата торган иде. Моңардан күршеләре көнләшепме, әллә күпсенепме, балын кыйбатсынганнар.

— Әнә кибеттән имән чикләвеге оныннан ясаган конфетны биш сумга алыгыз да ашагыз, үзенең тәме булмаса да, кәгазе бик матур, — дигән Кәлимулла бабай.

"МОННАН ДА ИСКЕСЕ БАРМЫ?"

Миннәхмәт абыйның бер яртыга акчасы җитмәгәч, эштән кайтып килүче Сәмигулла абзыйдан сорарга була. Сәмигулла абзый таушалган, ямаулы костюм кесәләрен актаргач:

— Әй, Миннәхмәткәем, акчаларым бу кәчтүмдә түгел, искесендә калган шул, — дигән.

— Синең тагын моңардан да искерәк кәчтүмең бармыни әле? — дип куйган Миннәхмәт абый да, ничарадан бичара булып.

"МЕНӘ СИҢА КУКИШ"

Бервакыт иртәнге чәйгә Мөхәррәм абыйның карчыгы тәмле итеп кабак пирогы пешерә. Икебезгә бер пирог җитәр әле, дип, тынычлап кына чәй янына утыралар.

— Бигрәк тәмле хуш ис килеп тора, рәхәтләнеп икәү генә ашарбыз инде, — ди Мөхәррәм карт.

— Бисмилләһны әйтеп утыр, алайса ашый да алмассың, — дип әйтеп тә бетерә алмый хуҗабикә, күрше бригадир Вәлиәхмәт абзый килеп керә.

— Әйдүк, бигрәкләр дә мактап йөрисең, Вәлиәхмәт, сиңа дигән бер пирог калды, — дип ычкындырып җибәргән Мөхәррәм карт. Күршесе, шуны гына көткәндәй, өстәл артына утырып, пирогны сыпыра да рәхмәтен әйтеп чыгып та китә.

Бу хәлгә кызарынып-бүртенеп утырган карчык:

— Менә шулай ул, авызың сүз ясый белмәсә, бисмилләһны да әйтә алмагач, пирог урынына сиңа, — дип кәҗә тоягы күрсәтә.

"ЗУР КҮЛ БУЛА"

Мөхәррәм бабайның сыеры булмый. Күршеләре аңа сиксән сумга сыер алырга тәкъдим ясый.

— Сыер алсаң, көтү көтәсе, печән әзерлисе була, ә сиксән сумга катык алсаң, бер зур күл була, — дип куйган бер нәрсәгә дә исе китмәгән Мөхәррәм бабай.

"БИРЕРМЕН МИН СИҢА БРАТЫҢНЫ"

Кичке эңгер-меңгердә ике дускай салмыш килеш машинада кайтып киләләр икән. Боларның юлында бер җәяүле очрагач, моның бераз булса да хәмергә кушылырлык сәмәне бардыр әле, дип, утыртырга булалар.

Рифкать абый, машинаны туктатып:

— Сәлам, брат, әйдә утыр! — ди юлчыга.

— Бирермен мин сиңа братыңны! Исерек чуаш, әллә атаңны танымый башладыңмы инде? — дигәч кенә, Рифкать абый аңына килә.

"СИН БИТ САРЫК ТҮГЕЛСЕҢ"

Фермадан сарыклар югала икән, шуның эзенә төшә алмаганнар. Бервакыт Рәхимҗан салган баштан күршесенә ычкындырган:

— Аның бер нәрсәсе дә юк, сарыкның башына малахай кигереп, өстенә иске шинель ябасың да, җитәкләп китәсең. Кеше очраган вакытта, акырма инде исерек чуаш, син бит сарык түгелсең, атлый төш, дип, дәлше китеп барасың.

"СЫТЫП КЫНА КҮРСӘТЕРМЕН"

Харис абзый хатыны белән талашкан саен, хатыны аны кушаматы белән "бетле, бетле" дип, үчекли икән. Бу сүзләргә түзәр хәле калмагач:

— Әгәр дә мәгәр тагын бер шулай әйтсәң, үтерәм мин сине, — дигән абзый.

Мәһинур апа да шаяртып:

— Башка алай әйтмәмен, бетне бармак белән сыткан шикелле, сытып кына күрсәтермен, — дигән.

"ИПИ КУЫШЫНДА ЫШЫКЛАНЫП ТОРДЫМ"

Мөхәррәм абзыйның хатыны ипи пешергән саен ипиләренең эче куыш була икән.

Бервакыт хуҗа кеше иртән урманга утын әзерләргә китеп бара. Көне буе яңгыр ява, ә Мөхәррәм абзый өс-башы коры килеш кайтып керә. Хатыны, моңарга исе китеп:

— Кайда йөрдең, булдыксыз? Урман кискән кешенең өс-башы чылана, — дигән.

— Әнә, син пешергән ипинең куышында ышыкланып тордым, — дип хатынының авызын томалап куйган Мөхәррәм абзый.

"ИРЛЕГЕМНЕ ИТӘМ, БАРЫБЕР ЧЫКМЫЙМ!"

Харис абый салып кайткан вакытларында зур бәдәнле хатыны Мәһинур ападан курка торган була. Берсендә, тегесе бәйләнмәсен дип, кровать астына кереп качкан бу. Акчасы да калмагач, гаепле дә булгач, тын да алмыйча ята икән. Мәһинур апа ишек төбендә торган ботинкаларны күргәч, Харис абыйның өйдәлегеен белеп, аны кровать астыннан эзләп таба да, мич алдындагы кучарканы кулына алып: "Чык, хәшәрәт, бәреп үтерәм!" — ди. Харис абый горур кыяфәттә: "Ирлегемне итәм, барыбер чыкмыйм", — дип мыгырдаган.

"САЗЛЫ БУЛСА ДА ЯРЫЙ"

Элегрәк заманнарда авылда була бу хәл. Нәсимә апа, кибеткә барып, үзенә күлмәк тегәргә ситса алырга була. Кибетче Нәсибулла агай:

— Ситсаның бер төре генә калды, бераз саржасы гына, калганын алып бетерделәр, — ди.

Нәсимә апа, сүзне аңлап бетермичә, саржаның да аз калуын ишеткәч:

— Ярар, сазлы булса булыр, акчам бар вакытта бер күлмәккә җитәрлек булса, үлчәп бир әле, — дип әйтеп салган.

"ЕФӘК БИТ УЛ"

Өченче сыйныфта татар теле дәресе бара. Укытучы Гөлсинә апалары тактага үреләүреләү контроль эш яза. Гөлсинә үрелгән саен күлмәк күтәреләдә дә, эчке күлмәге күренеп китә икән. Алдагы партада утырган Марат, бу күренештән көлемсерәп:

— Апа, апа! Синең эчке күлмәгең күренә бит! — дип куймасынмы.

Ә Гөлсинә, бер дә исе китмичә:

— Күренсә соң! Ефәк бит ул! Кичә генә алган идем, — дип мактанып куйган.

"АЯККА КИРӘК ИДЕ"

Галимҗан абый Үзбәкстан якларыннан авылга кайтып төшә. Җылы якта аягына һәрвакыт галуш киеп йөрергә өйрәнгәнлектән, монда да үзенә галуш алырга була. Ул чорларда көнкүрешкә кирәкле вак-төяк товарларны авыл җирендә җигүле ат белән сатып йөриләр иде. Галимҗан абый үзенә "заготовитель"дән галуш сорагач, сатучы галушның йомыркага гына икәнлеген әйтә.

Галимҗан абый, бу сүзнең мәгънәсен аңлап бетермичәме, әллә шаяртыпмы:

— Юк шул! Миңа йомыркага түгел, аякка кирәк иде!? — дип куя.

"ТЕЛӘСӘ НИЧЕК АҢЛА"

Сәмигулла абзый колхоз көтүен көткән вакытта, райком секретаре Фәйрушин килеп төшә. Хәл-әхвәл сорашкач, төп мәсьәләгә күчә:

— Ничек итеп сөтне арттырып була, берәр киңәш бирә алмассыңмы, Сәмигулла абзый?

— Менә бу кәҗә токымлы, кечкенә җиленле сыерларны алыштырмыйча, берничек тә сөтне арттырып булмаячак.

— Бу сүзләрне ничек аңларга?

— Теләсә ничек аңла, иптәш секретарь. Бер литрлы банкага ике литр су сыймаган шикелле була инде ул, — дип җавап бирә тапкыр сүзле Сәмигулла абзый.

"ИДӘН АСТЫННАН СӨЙЛӘП ТОРА ТОРГАНДЫР"

Бу хәл Чирмешән районының Лашман авылында "эшләпә" радионы яңа гына колхоз кәнсәсенә куйган чорда була. Авыл халкы җыелып, кәнсәгә радио тыңларга баралар. Шунда берәве, бу гаҗәп хәлгә исе китеп:

— Шуңарга ышанасызмы? Ничек итеп тимер чыбык буйлап тавыш килсен? Кем дә булса идән астыннан сөйләп тора торгандыр әле, — дип шиген белдергән.

"НИЧЕК ТУЙДЫРЫРСЫҢ?"

Лашман авылында радио яңа гына кертелә башлаган чор. Шуңа күрә ул санаулы кешеләрдә генә сөйли. Бер көнне Фатыйма әбиләргә күршесе килеп керә. Алдагы өйдә гөр килеп радиодан Камал театры спектакле бара.

— И-и, Фатыйма! — ди күршесе, пышылдап кына. — Кунакларың бик күп икән, башка вакыт керермен. Ничек ашатып туйдырырсың инде боларны, — дип чыгып китә.

"КАЗАН СӨЙЛИ"

Авылга радио кертә башлаган чор. Беренчеләрдән булып радионы Фатыйма әбиләргә кертәләр.

Шулай беркөнне аларга Шәмсиҗамал әби килә. Өйгә керсә, беркем дә юк. Тып-тын. Арлы-бирле йөренгәч, китәрмен инде, дип торганда кинәт кенә радио: "Казан сөйли", — дип кычкырып җибәрә. Шуннан Шәмсиҗамал әби куркуыннан тәһарәтен югалтып чыгып йөгерә.

"КАЙЧАН ӘЙТЕРЛӘР"

Чирмешән районында бригадир иртәнге нәрәтне радио аша әйтә иде. Төрле-төрле белдерүләрне дә авыл халкы шуннан ишетеп торды: кем малын суя, клубта нинди кино була, үлем-китем һ. б.

Шулай бервакыт Хөсния әбигә күршесе керә:

— Хәлең ничек, әби. Нишләп ятасың?

— Менә радиодан кайчан Хөсния үлде, дип әйтерләр икән дип көтеп ятам.

"БЕЗНЕКЕ ЯҢАРАК"

Фатыйма әби бер көнне башка чыккан улы Миндарларга кунакка килә. Өйдәгеләр телевизор карап утыралар икән. Телевизорның да яңарак кына чыккан вакыты.

— Карале, улым! — ди әби. — Синең телевизорыңның кешеләре күбрәк ахрысы.

— Әйе шул, эни. Безнеке яңарак бит.

— Ә-ә, шулайдыр шу-у-ул, рәте бар икән, — дип куя әби.

"САБЫЙЛЫГЫМ БЕЛӘН ГЕНӘ ЙӨРИМ"

Җиденче дистәсен куып килүче Рәхимҗан әзи берара чирләбрәк китә.

— Хәлең ничек, Рәхимҗан? — дип сорый аннан күршесе.

— Сорама әле юкны! Сабыйлыгым белән генә йөрим!

"СӘЛАМЛӘШҮ"

Бер көнне бер дустыма чылтыратам. Үземчә итәгатьле итеп:

— Бисмиллаһир-рахман-иррахим, исәнмесез, — дип башлаган идем, ире белән әйткәләшә-әйткәләшә трубканы хатыны күтәрде:

— Фәләнеңне себерим. Исәнмесез.

"РӘШИТ КАПЧЫКЛАРЫ"

Бервакыт Рәшит, колхоз рәисе янына кереп, өч капчык фураж сорый. Персидәтел өч капчык фуражга рөхсәт кәгазе язып бирә. Рәшит бишәр центнер сыешлы зур ашлама капчыклары алып, амбарга юнәлә. Амбар мөдире Әхмәт абый бу капчыкларга карап тора да:

— Сиңа, туган, бу капчыкларны тутыру өчен ярты амбарның фуражын тояргә кирәк бит, — дип куя.

Шуннан соң авылда халык арасында берәр төрле “зерно” төяргә туры килгәндә: “Монда Рәшит капчыклары кирәк”, — дигән сүз кереп калды.

"ҮЗЕМДӘ ДӘ УТЫЗ СУТЫЙ"

Җәйге матур көннәрнең берсендә Рәҗәп Чаллыда яшәгән Рәфыйк абыйсына кунакка килә.

Абый кеше кунакны сый-хөрмәт итә. Аннан:

— Әйдә, энекәш, бакчага барабыз, күреп китәрсең, — ди.

— Аңысы кирәкмәс, абый, — ди Рәҗәп. — Авылда үземдә дә утыз сутый бит. Тәмам гарык.

"ЯЛГЫЗ КАЛДЫМ"

Бервакыт Хәлим дусты Галиәхмәткә шалтырата. Шалтыратуын шалтырата да, икенче кешеләргә эләгә.

— Миңа Галиәхмәт кирәк, — дигәч, трубканың икенче очыннан:

— Вәлиәхмәтем ташлап китте, Галиәхмәт дигәнең белән танышырга өлгермәдем, дөньяның кызыгы бетте шул әле — үзем генә калдым, — дип борчулы тавышлы хатын-кыз телефон трубкасын куя.

"ТРАМВАЙ МАШИНА ТҮГЕЛ"

Бибинур апа юлда очраган машинага утырып шәһәргә барган. Шәһәр эченә кергәч, шофер, трамвай юлы аркылы чыкканда, Бибинур ападан:

— Машина юкмы? — дип сораган.

Апабыз үз ягындагы тәрәзәдән борылып караган да:

— Машина юк, — ди икән.

Ул да булмаган, боларның машинасына трамвай килеп төртелгән. Нишлисең, трамвай машина түгел шул.

"ИДИ СЮДА, ГАЛОШ"

Хәтимә апа шәһәргә баргач, галош эзләп кибеткә чыгып киткән. Ул чакта әле товар прилавка артында, кибетчедән сорап аласы. Үзенә кирәкле галошларны кулы белән алып килеп бирә алмаганга һәм русчасы бөтенләй дә булмаганга, озак кына аптырап торган да, бөтен белгән сүзләрен җыеп:

— Иди сюда, галош! — дип әйтеп салган Хәтимә апа.

"НИЗАМ БЕЛӘН НӘҖМИ"

Җәйге эссе көн. Низам белән Нәҗми, юлда барганда бик сусаганнар да, урыс авылында туктап, бер марҗадан су сорап кермәкче булганнар. "Син кер дә, син кер", дип шактый гына тарткалашканнан соң, беренче булып Низам кереп киткән. Марҗа сулы кисмәккә төртеп күрсәтеп: "Возьми", — дигән.

Низам: "Нәҗми, сине чакыра бугай ул", — дип кире йөгереп чыккан.

Нәҗми кергәч, гаҗәпләнеп, ачуы чыккан хатын: "Не дам!" — дип кырт кискән. Инде Нәҗми дә: "Низам дип әйтә, сине чакыра бит ул!" — дип аптырап килеп чыккан.

"БЕЗГӘ ДӘ ЯРАР"

Хәлим хатыны белән авылдан Яңа елга Чаллы шәһәренә кунакка килә. Өйдә сыйлангач, Яңа ел чыршысы янына таудан шуарга баралар. Шул вакыт Хәлим, бозлы тауда егылып китеп, бүреген югалта. Бүрек бик әйбәт булмаса да, ялан баш кайтып булмый бит инде авылга. Хатыны, нишләргә инде, дип борчылып торганда, берәү егылып китеп бүреге тәгәрәмәсенме. Хәдичә дә озак уйлап тормыйча:

— Безнекен алдылар бит! Безгә дә ярар, — дип, ондатра бүрек белән авылга кайтып китәләр.

"ЙОНЫ ДА ЮК ӘЛЕ"

Бу хәл алтмышынчы еллар азагында тырышып-тырышып хөкүмәт планын үтәгән чорларда була.

Районнан колхоз идарәсенә шалтыраталар:

— Хуҗалыгыгызда башка күрсәткечләрегез бик әйбәт. Нигәдер күкәй йөкләмәсен үти алмыйсыз! Ферма тулы сарыкларыгыз, күкәй планын йон белән капласагыз да ярый, — дигән вәкил.

Колхоз рәисе аптырашта калып:

— Булуын була да, бу вакытта җәй көне шәрә тәнгә күкәй капларлык йоны да юк бит әле, — дип куйган.

"АКЛЫККА АК"

Көзге пычрак вакыт, колхозда сөт тапшыруның иң кимегән чагы. Районнан вәкил колхоз идарәсенә шалтыратып:

— Сөт ничек анда? — дип кызыксына.

Идарәдә дежур торучы абзый:

— Сөт ул аклыкка бик ак, юллары аның пычрак, фермага азык та кертерлек түгел, — дип шома гына җавап кайтара.

"ВЫ ЖИВЫ ЧТО ЛИ?"

Казан паркларының берсендә була бу хәл. Милициянең өч дежур патруле җәйге матур төндә тәртип саклаганнан соң, иртәнге якта үлән өстенә ятып ял итеп алырга уйлыйлар. Шулвакыт бер марҗа әбие иртә таңнан эте белән прогулкага чыккан була. Куаклар арасында хәтфә үлән өстендә аунап яткан өч милиционерны күреп, үтергәннәр ахрысы боларны, дип телефон будкасына кереп, 02 гә шалтыратып, күргәннәрен сөйләп бирә.

Дежурдагы милиционер бу хәбәрне алгач, тревога сигналы бирә. Бу сигналны йоклап ятучы милиционерлар да трубкаларыннан ишетеп, урыннарыннан сикереп торып, өч үле хезмәткәрләрен эзләп сукмакка йөгереп чыгалар. Шул вакыт милициягә хәбәр биргән әби боларга каршы очрап, калтыранган тавыш белән: "Вы живы что ли?" — дигәч кенә, егетләр тынычланып, хәлне аңлап, үз юллары белән китеп барганнар.

"ҮЗЕҢНЕКЕН БЕЛ!"

Базарда сату итүче Луиза әшен күршесе Эльзага тапшыра да: "Утны сүндерергә тиешләр иде, суыткычтагы ризыклар эреп беткәндер инде", — дип, ашыга-ашыга өенә кайтып китә.

Луиза өеннән килгәч, Эльза кызыксына:

— Нәрсә, пилмәнең җебегән мәллә?

Эльзадан гел төртмә сүзләр генә ишетергә күнеккән Луиза, күрәсең, яңа гына өенә кайтып килгәнен оныткан, шуңа күрә кинәт кызып китә:

— Кемнеке җебегәндер әле! Үзеңнең пилмәнеңне бел башта!

"МИН ДӘ ПЕШТЕМ БИТ"

Гали эштән нык кына тамагы ачыгып кайта да хатыны Саниягә аш бүләргә куша. Сания кайнар ашны өстәлгә китереп куя. Гали токмачлы кайнар ашны ашыгып кабып, авызын пешерә. Хатынына сиздермәскә тырышып:

— Нигә инде сап-салкын аш китердең? — ди.

— Нинди салкын булсын инде? Яңа гына пешкән аш бит, — дип Сания үзе дә ашны кабып карап авызын пешерә.

— Соң син миңа әйттеңме!? Мин дә пештем бит, — дип куйган хужа кеше.

"ХӘЙЛӘКӘР АЛЫМ"

1975 ел. Чаллыда ул вакытта бер-ике җирдә генә сыра сагалар иде. Андагы халык, андагы чират...

Бер ял көнендә кулыма ике банка тоттым да, "Универсам" янына киттем. Карыйм, чиратта алдарак ике танышым басып тора. Банкаларны боларга китереп тоттырдым. Озак та үтми, боларга тагын дүрт банка китереп бирделәр. Шулвакыт сатучы сыра бетеп килүен хәбәр итмәсенме! Китте сугыш... Мин дә килеп кушылдым. Һавада банкалар оча гына... Ул да түгел, милиция дә килеп җитте, сугыш чукмарларын берәм-берәм җыештыра да башладылар. Ярый әле, минем бәхеткә, "Универсам" каршында коляскада бер бәби утыра иде. Шул бәбине арбада тирбәткән булып, котылып калдым.

"БЕР ҮК ҖИҢЕЛДЕ ДИП УЙЛАМА"

Урам аркылы кара-каршы ике күрше-ике хатын җилкапка рәшәткәсе арасына башларын тыгып, берсеннән берсе уздырып, төкерекләрен чәчә-чәчә, орышышпмы-орышышалар.

Менә бервакыт Хәмдия түти туктап кала да:

— Син, Галимә, мине бераз көтеп тор. Берүк җиңелде дип уйлама. Мин камыр куйган идем, хәзер шуны гына карап чыгам да кирәгеңне бирәм әле, — дип, тә-тә-тә-тә... кирә-килә кереп китә.

"ЯШИСЕҢ ИНДЕ ҮЛГӘНЧЕГӘ КАДӘР"

Гариф абзый, озак кына чит җирләрдә йөргәч, авылына кайтып төшә. Кайтканның икенче көнендә урамда кордашы Барины очрата. Хәл-әхвәлләр белешкәч, Бари абый операция ясатып бер бөерен алдыруы турында әйтә.

— Юкка борчылма, кордаш, — дип тынычландыра аны Гариф абый. — Бер бөер белән дә бик озак яшиләр.

— Әйе... Яшисең инде үлгәнче, — дип җөпли аның сүзләрен Бари абый.

"ИШКӘНСЕҢ ИШӘК ЧУМАРЫН"

Элегрәк заманнарда счетчик электр энергиясен санамасынга пленка кыстырып куялар иде. Малае белән килене эшкә киткәч, Мөхәммәт бабай карчыгы белән чәй эчеп утыралар икән. Шул вакыт урам як тәрәзәдән счетчик тикшерүче килгәнә күренә. Әби, улының счетчикка нәрсәдер кыстырып киткәнен әйтеп, картына аны тизрәк алырга куша.

Мөхәммәт бабай күрер-күрмәс күзләре белән:

— Монда нәрсәдер асылынып тора, — ди.

— Тартып ал! Озак казынасың! — ди әби.

Электрик счетчикны карый-карый да:

— Пленкасы тора, пломбасы өзелгән, — дип куя.

— Ишкәнсең икән ишәк чумарын! — ди әби, бабайга карап.

"СИҢА КИЛӘ ИДЕ БИТ"

Галимҗан абый көзгелеккә дип симерткән үгезен суярга була. Менә күршеләре кереп, үгезнең аякларын бәйлиләр дә суеп та җибәрәләр. Аякларына бәйләнгән бау черек булып чыга һәм үгез сикереп тора да чабып китә.

Аптыраашта калган Галимҗан абый хатынына кычкыра:

— Маһинур! Маһинур! Тизрәк чиләгеңне алып чык әле. Син чакыргач, сиңа килә иде бит ул!

Моны ишеткәч, бөтен ирләр бот чабып көләләр.

"ФАМИЛИЯСЕ ТУРЫ КИЛМӘДЕ"

Рөстәм, югары белемле булса да, пенсиягә кадәр заводта гади эшче булып эшли. Иптәшләре: "Дипломың була торып, нигә нәчәльник булмадың?" — дигәч:

— Әй, егетләр, нәчәльник була торган эшкә минем фамилиям туры килмәде шул, — дип шаяртып куйган.

"НАЕН, НАЕН"

Чаллыга ГДРның Социалистик бердәм партиясе генераль секретаре Хонеккер киләсе дип, оста пешекче Мөхтәрәмә ападан күпереп торган бавырсак пешертәләр. Һәм дә матурлык өчен дип, икенче подноска кибет чәк-чәге дә куеп, Хонеккерны самолеттан Чаллының ике җәүһәр кызы каршы ала.

Бавырсак белән сыйланасы урынга нимес кунагы подностан чәк-чәк алып каба. Аны бераз авызында әйләндергәч, каты булу сәбәпле микән, чәк-чәкне кулы белән авызыннан ала да, шыпырт кына җиргә төшереп җибәрә.

Райком секретаре Беляев бу хәлне күргәч, бик уңайсызланып, бавырсак тоткан Гөлзада Рзаевага:

— Бар инде, машинасына булса да илтеп куй, — ди.

Гөлзада ханым бавырсагын күтәреп Хонеккер машинасына якынлашкач, тегесе:

— Наен-наен, данке-данке, — ди дә, тизрәк шылу ягын карый.

"ТУГАН ЯК ИСЛӘРЕ"

Композитор Ринат Гобәйдуллин белән җырчы Габидулла Хөрмәтуллинның 88 нче елда концертлардан соң "Запорожец" машинасында Самара өлкәсеннән кайтып килүләре икән. Үзебезнең Татарстан чигенә чыккач, Габидулла шатланып:

— Туган як кырларының исе дә тәмле, кырлардан салам яндырган исләре килеп тора, — дигән.

Ринат шулвакыт артка таба борылып караган да:

— Юк шул, Габидулла туган! Бу төтен салам исе түгел, двигательгә ут капкан бит, шуның исе чыга! — дип кычкырып җибәргән ди.

"АНЫ СУКТЫРА КАЛДЫЛАР ӘЛЕ"

Габделхакларга якын дуслары Тәлгать җәмәгате Гөлчирә белән шәһәрдән кунакка кайталар. Болар яхшы гына сыйланып, Яңа елны каршы алгач, сәрхүшләнгән хуҗаны өйдә калдырып, өчәүләшеп яңа ел чыршысы янына таудан шуарга чыгып китәләр.

Бераздан соң Габделхак та уянып урамга чыга. Караса, битләре тырналып, күз төпләре күгәренеп Тәлгать белән Гөлчирә кайтып киләләр.

— Сезгә нәрсә булды? Минем хатын кая калды? — дип сораган Габделхак.

— Безне суктырып җибәрделәр, ә синең хатыныңны суктыра калдылар әле, — дигәннәр кунаклар.

Хәл болайрак була: кунаклар таудан шуганда, Тәлгать, егылып китеп, олы бәдәне белән бер яшь җилкенчәкне сыта яза. Кайткан кунакларны танып бетермәгәнгә күрә, яшьләрдән боларга бераз йодрык эләгә. Коткарырга дип арага Габделхакның хатыны керә. Тегеләр шул арада ычкыналар.

Менә шуннан соң авыл җирендә берәр җиргә барганда, йә эшкә берәрсе соңарса:

— Хәзер килеп җитәр, "аны суктыра калдылар әле", — дигән сүз халык телендә калды.

"СИНЕ ҮРТӘМИЛӘР БИТ!"

Өч дус, Казанда студент булып укып йөргән вакытта, мунчага баралар. Җәдит белән Галиәхмәт саунада утырган вакытта, Кадыйр бассейнга китә. Бассейнда чегән малайлары сикерешеп уйнаган чакта, бер иптәшләрен "татарчонок" дип үчеклиләр икән. Шунда Кадыйрның бу күренешкә хәтере калып кайта.

— Кара, үзләре чегән малайлары булсалар да, "татарчонок" дип үртәшәләр.

Җәдит, Чирмешән егете, Кадыйрны:

— Сине үртәмиләр бит! "Мишәр" дип әйтмиләр. Нигә "татарчонок" дигән сүзгә кимсенәсең соң әле? — дип тынычландыра.

"ЕШРАК БИРЕРГӘ КИРӘК"

Хәмит авылда мулла бабайдан:

— Садаканы ничек бирсәң әйбәт? Азракмы, күбрәкме? — дип сораган.

Мулла бабай сакалын сыпыргалап:

— Садаканың азы-күбе юк, улым! Азрак биргән очракта, ешрак бирергә кирәк! — дигән.

"ЧИП-ЧИСТА ПИСУКТАН"

Хәсәнҗан бабай кунакларны әйбәт кенә сыйлагач, бал белән чәй эчертә.

Гата бабай телләрен ялап:

— Балың "липовый" ахрысы? — дигән.

Хәсәнҗан бабай күршесенең юкә балы турында сүз алып барганлыгын аңламыйча:

— Ниткән сүз ди ул? "Липовый" имеш! Нурлат шикәр заводының чип-чиста писугын кушып ясаган бал бит, — дип серне ачып салган.

"ТӘКӘ КЫЧКЫРА БАШЛАДЫ"



Заманында Лапман авылының сукыр Мәгъсүм абыйны, оста гармунчы булырак, район җирлегендә дә яхшы беләләр иде. Аның гармунга өйрәнүе дә бик кызык кына була. Акча юк заман, бу рөхсәтсез-нисез атасының тәкәсен Сибгат абзыйдан гармунга алыштырып кайта. Аны мунчага яшереп куя. Берничә көн үтеп, өйдәгеләр бераз тынычлангач, Мәгъсүм абый төнлә белән мунчада моңланып утыра икән. Тора-бара атасы, бу хәлне сизеп, карчыгына:

— Әнә, югалган тәкә мунчада гармун булып кычкыра башлады, — дигән.

"КУТЫР ЧЫГАРЫП БУЛМЫЙ"

Сугыш ветераны Галимулла бабайны инвалидлыкка комиссия узарга шәһәргә алып киләләр. Табибка юк-бар болячкаларын әйтеп, төнлә вакытсыз уянып йөрүләрен дә сөйләгәч, табиб бабайдан кай җирләре авыртуын сорый. Сугышны аркылыга-буйга йөргән коммунист бабаебыз:

— Авыртмаган җиргә кутыр чыгарып булмый инде, — дигән.

"ПЕСИ-КАРАК"



Агач ишекләрне тимер ишекләргә алыштырып мәш килгән чаклар иде.

Төн уртасында ишектә кыңгырау чыңлады. Ачсам, ике милиционер басып тора.

— Берәр сәер нәрсә ишетмәдегезме? — диләр.

— Юк, ул-бу сизелмәде, —дим.

Милицияне күршем Зөлфия чакырткан икән.

— Әгәр дә тагын берәрсе ишекне ачарга тырышса, стенага шакырмын, — диде күршем.

Озак та үтмәде, Зөлфия шартлы сигналны бирде. Мин, кулыма газовой ачкыч тотып, ишекнең "глазогын"нан карыйм, кеше-фәлән күренми, лифт тавышы да ишетелмәде. Иплән кенә ишекне ачып җибәргән идем, бер кара песи бүлмәгә йөгереп кереп тә китте. Минем ул турыда уйлау юк, лифт тавышы да ишетелмәгәч, тугызынчы каттан аска йөгереп төшеп киттем. Беркем дә юк.

Хәл болай булып чыкты. Сигезенче каттагы песи хуҗасы да тимер ишек куйдыргач, бу төнге кунагыбыз тугызынчы катка күтәрелеп, бердәнбер алыштырылмаган агач ишекнең тоткасына үреләп, элеккеге гадәте буенча, тәпи белән шыкылдата икән. Минем күршеләремә, курыкканга куш күренә, дигәндәй, карак булып күренгән чакырылмаган төнге кунагыбыз "песи-карак" булып чыкты.

"АЛЫП КИТ ПЕТКӘН БОЗАВЫҢНЫ"

Бәдри абзыйның бозавы арканлап куйган җирдән ычкынган да юкка чыккан. Бозавын эзләп Бәдри абзый күрше чуаш авылына юл тота. Илья дәдәйләрдә ят бозау бар дип ишетеп, аларга керә. Илья дәдәй абзарыннан ишек алдына ике бозау алып чыккан. Икесе дә ак кашкалы бу бозауларның берсе карап торырга көр генә күренә, икенчесе бераз кайтыштрак икән.

Бәдри абзый, аптырап тормый:

— И, матурым, мондамыни син? Әйдә, җаным, кайтабыз, — дип бозауның йомрыгына таба бара башлый. Моңа түзеп тора алмаган Илья дәдәй:

— Әнә, алып кит петкән бозавыңны, — дип ябыграгына таба төртеп күрсәтә икән.

"ШИФОНЕР АРТЫННАН ЧЫККАННАРЫ ДА ЮК"

Галимҗан абзыйның кече малае башлы-күзле булгач, Үзбәкстан якларыннан туган абыйлары кайтып төшә. Өйгә кереп хәлә-хвәл сорашкач:

— Яшьләр кая соң? Нишләп яталар? — ди ул.

Әти кеше, бер дә исе китмичә генә:

— Кем белгән инде аларның нишләп ятканнарын? Шифонер артыннан чыкканнары да юк, — дип куя.

"ЛУЧШЕ В МАГАЗИНЕ КУПЛЮ"

Әхмәт бабайның өченче улы марҗага өйләнеп, Калининград шәһәреннән авылга кайтып төшә. Җәй көне, матур вакыт, как-раз бәрәңге өяр чак. Кунакларны мунча ягып сый-хөрмәт иткәч, икенче көнне бакчага бәрәңге кәтмәннәргә алып чыгалар. Көн эссе, тамак кибә, җитмәсә, килен тулы бәдәнле, гомерендә кулына кәтмән тоткан кеше түгел икән. Бер-ике буразнаны паф-пыф килеп кәтмәнләп чыга да, аты-юлы белән:

—Не надо мне вашей картошки! Лучше в магазине куплю, — ди дә, җыенып Калининградына кире китеп тә бара.

"УРАМДА ИШЕТКӘННӘРДӘН"

Ике хатын үзара сөйләшеп бара. Берсе сорый:

— Синең кызың кияүгә чыктымы әле?

Икенчесе, уйланып барган халәттә:

— Әй, чыкты бугай!

"КИЛЕННӘН БАШ-АЯК"

Әтисе Хәйрулланы: Сиңа өйләнергә вакыт җитте", — дип бик нык кыстагач, малай өйгә булачак берничә киленне алып кайтып күрсәтә. Ата кешегә ник берсе ошасын. Чәче кыска, тырнагы озын, тегесе-монысы һәм башкасы. Соңгы чиктә кара чәчле, озын толымлы, зәңгәр күзле, тулы бәдәнле, буйга кечкенә лаптак кына бер кызны алып кайта. Ата кеше киленне әйләндереп-әйләндереп карап чыга да:

— Бусы бөтенләй тач анаң, күз карашларына кадәр охшаса да охшар икән, — дигәч, малай бу сүзләргә шатланып:

— Әни чалымнары булганга күрә алып кайттым да инде, — дигән.

— Юк шул, улым! Анаңа охшаган булгач, булмый инде, анаң бик усал, буйсынырга яратмады, үзенеке үз булды, шулай булгач, киленнән баш-аяк, — дип кул селтәгән.

"ДУСЛАРЫҢ ДА ТУЙГАННАР"

Дүртенче тапкыр өйләнгән кияү, туйда кызган баштан:

Төштем авыр хәсрәтләргә,
Дусларым, аралагыз,

— дип җырлап җибәргән.

Кияүнең ничәнче тапкыр өйләнүенә төртте-реп, дусты Мортый тора да:

Безнең асыл туйларга
Чүлмәк тезеп куйганнар.
Теләп алган хәсрәтеңнән,
Дусларың да туйганнар, — дип җырлап биргән.

"ӘЙБӘТ БУЛГАН БӘКӘЙ"

Фәрит булачак бабасына кыз сорарга кайткач була бу хәл. Болар икәүләшеп сөйләшә-сөйләшә матур гына бер сарыкны алып чыгып суялар.

Бабай кеше өйдән ит салырга савыт алырга кергәч:

— Ничек соң кияү? Әйбәтме? — дип өйдәгеләр сорап куялар. Бабай бераз колакка да саграк икән.

— Бик тә әйбәт булган бәкәй, нык симез булган үзе, — дип, савытка үрелгән.

"ҮЗЕМНЕКЕН ИШӘМ БИТ"

Кияү белән бабай базарга машина сатарга барганнар. Көзге көн, коеп яңгыр ява. Кияү арткы якта үзе белән алып килгән кабартмаларны бер-бер артлы сыдырып утыра.

Бабай үз алдына сөйләнеп:

— Ну бу яңгыр ишә дә ишә. Машинаны килеп караучы да юк!

Кияү бабайның сөйләнгәнен аңламыйча:

— Ишсә соң! Әллә синекеме?! Үзем белән алып килгәнне ишәм бит, — дип куйган.

"ДҮРТ АЯКЛАП ЙОГЫРТА"

Аш булгән вакытта кайнана киленгә:

— Карале, кызым, монда аш өстендә нәрсәдер йөзә, — дигән.

— Энкәй, ул ашның туртасы, туртасыдыр...

— Туртасын турта да, ул бит дүрт аяклап йогырта, — дип тараканны алып ташлаган.

"ТОКМАЧТАН КОТЫЛГАННАР"

Капка төбендә ике карт сөйләшәләр.

— Кара әле, теге Гыйльмулланың малае читтән марҗа ияртеп кайткан диләр.

— И, яхшы булган! Котылганнар икән Гыйльмулланыкылар токмачлы аштан.

"ЗАТО ЮГАЛМЫЙ"

Хәлил эчкән килеш еш кына баш киемен югалта икән. Бервакыт күршесе, моның башында таушалып беткән иске кепка күреп:

— Нигә козырегына кадәр бөгәрләнгән кепка белән йөрисең? — дип сораган.

— Зато югалмый, югалса да, бу Хәлил кепкасы, дип китереп бирәләр, ә яхшысы югалганда белүче дә юк, — дип җаваплаган Хәлил.

"МИҢА САЛМА. МИН ЭЧМИМ"

Сиксәненче еллар башы. Колхоз фермасында эшләрнең гөрләп торган чагы. Ат җигүчеләр эштән соң бераз салгалап кәефләрен дә күтәрәләр. Шулай бервакыт, кышкы салкын көннәрнең берсендә, ферма котельныенда җылынып торалар икән болар.

Су буенда яшәүче Бәян аптига сенаж сатып, алып килгән яртылары да бар. Сыфыян абзый бүлүче. Иң элек ул Рәхимҗан әзигә салып бирә. Тегесенең стаканны бушатып өлгерүе була, ишектән бозаулар караучы хатыны Миннур апа очып килеп керә. Шаянлыгы һәм тапкырлыгы белән дан казанган Рәхимҗан әзи аптырап калмый:

— Сыфыян әзи, миңа салма. Мин эчмим, — ди чыраен сытып. Бу сүзләрдән канатланган Миннур апа:

— Эчмә, эчмә, Рәхимҗан! Кирәге юк, — дип кычкыра.

— Юу-ук, карчык. Эчмим. Әллә мин алкашмы болар белән эчеп торырга.

"ЗӘМ-ЗӘМ СУЫ"

Кибеттә җыелышып дүрт кешегә бер шешә "московский" аракысы алалар. Аракы салкын булу сәбәпле, мич алдында торган кайнар сулы чиләккә утырталар. Сап-салкын аракы шешәсе кайнар суда шартлый. Соңгы акчаларын җыешып алынган ярты да әрәм булгач, пишләсеннәр, чиратлап кружка белән суга кушылган аракыны талаша-талаша эчә башлыйлар.

Шунда бәләкәй бәдәнле Сәлимҗан абый түзми:

— Егетләр, талашмагыз! Мин бүтән эчмим. Корсагым күпте бу "зәм-зәм" суыннан, үзегез генә эчеп күбенегез инде, — дигәч кенә иптәшләре тынычлап калалар.

"ҺАУ-ҺАУ"

Галимҗан абый төшергәләп кайтырга ярата. Шулай бер көнне, бераз чеметеп кайткач, моңарга хатыны ачуланып:

— Оятсыз, тагын эчеп кайттыңмы? — ди.

Галимҗан абый:

— Юк, карчыгым, эчмәдем, — дип аклана.

— Әйдә миңа таба өр әле, алдалап торма! — диюгә, Галимҗан абый эт кебек тешләрен ыржайтып: "Һау-һау", — дип өреп куйган.

Хатыны, иренең бу оятсызлыгына түзә алмыйча, уклау белән куып киткән.

"ҮЗЕМ ЭШЛӘП АЛГАН"

Бу хәл 1985 нче елның җәендә була. Сәлимнең егет чагы. Чаллыда торып эшләп йөри. Кошчылык фабрикасыннан яңа гына малосемейка биргәннәр үзенә. Авылдан армиядә бергә хезмәт иткән дустыннан туйга чакыру килә. Егет, уйлап та тормыйча, икеләтә шатлык белән авылга китә. Туй бик күңелле уза. Кунакны бик каты сыйлыйлар. Аның хәтта өйләренә, әнисе янына кайтып җитәрлеге дә калмый, урам кырыендагы бер баз куышына көч-хәл белән кереп егыла. Моны күреп калган һәм алар ягына кайтучы егетләр килеп: "Әйдә, Сәлим абый, өеңә кайтарабыз", — дигәч, Сәлим җавапны кыска тота: "Китегез моннан! Үзем алган малосемейка. Кертмим берегезне дә!"

Бу мизгелдә ул үзен Чаллыда дип хис иткәндер, күрәсең.

"ШУНЫҢ БЕЛӘН ПЕТТЕ!"

Бервакыт Галимҗан абый күрше авылга чуаш дустына кунакка бара. Барып керсә — дусты исерек, хатыны моны кыйнап ята. Икенче тапкыр кунакка килсә, дусты хатынын бәргәләп маташа.

— Бу нинди хәл? Теге килүемдә хатының суктыра иде үзеңне, хәзер килгәч син тукмаклыйсың хатыныңны? — дип аптырый Галимҗан абый.

— Әй, Калимҗан дус! Шуны да пелмисең. Ике йөрәк пергә сугышсаң, сугышып үләргә пит, ә полай пер-перенне генә кыйныйсың да, шуның пелән петте! — дип куя дусты.

"БӨТЕНЛӘЙ РӘХӘТКӘ ЧУМДЫМ"

Әминә апаның кулбашлары сызлагач, шәһәрдән медицина спирты кайтарта. Моның көн дә сөртенеп йөргәнен һәм спиртын кая яшергәнен тормыш иптәше Харис абый күзәтеп йөри. Бервакыт, мәҗлестән соң башы авырткан Харис абый, түзә алмыйча, спиртны бушатып куя.

Әминә апа буш шешәне күргәч:

— Минем дару урынына сөртенә торган спиртны да эчкәнсең, оятсыз! — дип әрли.

— Карчыгым, нигә бер гаепсезгә бәйләнәсең? Синең кулбашың сызлаган шикелле, минем дә ашказаным сызлады, спиртны тыштан ашказаны турысына ышкыган идем, файдасы булмады, шуннан соң эчке яктан бераз сылагач, рәхәт булып китте. Мин шуның рәхәтенә чыдый алмыйча, калганын сөрттем дә, бөтенләй рәхәткә чумдым, — дип аклана абзыебыз.

"БАШ БЕТКӘН ИДЕ"

Фатыйх абыйның "Газик" машинасында эшләп йөргән чагы. Җәйнең бер матур көнендә җан дусты кунакка кайтып төшә. Ике дус төне буе сыйланалар.

Иртәнге сәгать бишләр тирәсендә бригадир килеп, күрше авыл фермасыннан дуңгызлар төяп, ит комбинатына илтергә куша. Фатыйх абый айнымаган баштан онытылып китеп, күрше авылга да тукталмыйча, дуңгызларсыз гына Казанга таба җилдертә. Ярый әле, бәхетенә каршы юлда бер бабай белән әби кул күтәрә.

Фатыйх абый туктый да:

— Бик утыртыр идем, дуңгызлар төягән идем шул, — ди.

— Әй, туган! Алдалап торма инде. Әрҗәң буш бит, — ди бабай.

Фатыйх абый шунда гына аңына килеп, бабай белән әбигә рәхмәт әйтеп: "Әле дә ярый, сез очрадыгыз, алайса баш беткән иде", — дип авылга кире кайтып китә.

"СПИРТНОЕ НЕ ПЬЮ"

Аракыга кытлык заманда Хәлим иптәшеннән фляга алып самогон куеп, бакчасын эшләп бетерергә була. Иптәшеннән алган фляганы капчыкка сала да, берни дә булмагандай автобус тукталышына чыгып баса. Капчыкны тукталыш кырына куя, үзе тәмәке кабызып автобус көтә.

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, шунда скамейкада бер исерек ята икән. Менә көтмәгәндә дежур милиция экипажы килеп туктый. Исерекне машинага алып утырталар. Чират Хәлимгә барып терәлә. Аның янында торган фляганы да ачып карагач:

— Нәрсә, әллә базарда бражка сатып йөрисезме? — диләр.

Бу хәлләрдән соң Хәлимгә: "Я ведь вообще спиртное не пью", — дип фляга белән саубуллашырга гына кала.

"НАСТОЯЩИЙ АРАКЫ"

Нык кына салып алган Хәлим, ярты шешә аракысын, иртәнгә баш төзәтергә дип, кухняда калдыра. Бу хәлдән туйган хатыны, аракыны уксус шешәсенә бушата да, суыткычка алып куя.

Иртән Хәлим шатланып баш төзәтергә дип кухняга чыкса, идәндә буш шешә утырып тора. Хатынына да бәйләнеп карый.

Хатыны берни дә белмәгәндәй:

— Бирән, дуңгыз! Шешәңне кичтән үк бушатып бетердең бит инде, — ди.

Хәлим, аптырап, суыткычны ача. Карый, уксус тора:

— Ни булса, шул булыр, баш авыртуга түзәр хәл юк, — ди дә, уксусны эчеп җибәрә. Беравык күзләрен чепелдәтеп торгач:

— Карасана, бу бит настоящий аракы! Уксуска аракы кушып ясый башлаганнар ахрысы, — дип, вак-төяк акчаларын җыеп кибеткә йөгерә.

"СИНЕҢ САСЫГАН САМОГОНЫҢА..."

Элегрәк заманнарда шәһәр тирәсендә яңа үсеп килүче бакчачылык ширкәтләрен тирә-юньдәге авыллардагы хуҗалык тракторчылары тирес белән тәэмин итеп тора иде.

Аракыга сусаган авыл тракторчысына бер "Белорусь" арбасы тирес китергән өчен берничә шешә самогон бирәләр дә, шуның белән вәссәлам!

Бервакыт тирес илтүче тракторчы икенче йөген алып килгәч, бакча хуҗасы бәяне бераз төшерергә ниятләп:

— Әй, дус кеше! Синең элек китергән тиресеңнән бозау үләксәсе чыкты бит, — ди.

Тракторчы махы бирәсе килмичә:

— Синең сасыган самогоныңа колхозның нәсел үгезен салып килә алмам бит инде, — дип җавап бирә.

"ХАТЫН ГЫНА ЯНЫНА ЯТКЫРМЫЙ"

Көзге урып-җыю эшләре тәмамлангач, колхоз рәисе, комбайнчыларын кырда сыйлый. Икенче төрле әйткәндә "бохатай" ясый. Шунда берәүгә кызган баштан зәм-зәм суы җитеп бетми бит. "Иптәш рәис, тагын бераз юкмы соң?" — дип сорый бу. Рәис, ни әйтергә дә белмичә, камыл арасыннан йөгереп баручы тычкан баласына күзе төшеп, ярым шаяру белән: "Менә шуны тотып ашасаң, бер чирек аракы куям", — ди. Аракыга сусап тамагы кипкән комбайнер агай, кызган баштан теге тычкан баласын җан-тәслим кылып ашап та җибәрә. Кырчыларга бер чирек аракыдан соң (6 шешә) бик күңелле була.

Икенче көнне иптәшләре теге агайдан:

— Ну ничек соң? Тычкан баласы эчеңдә чинамадымы? — дип сорыйлар.

— Тычкан баласы чинамый да, ну хатынның чинавына чыдар хәл юк. Әле янына да яткырмады, каһәр суккыры. "Нишләп мин тычкан ашаган кеше белән ятыйм? — ди. — Адәм мәсхәрәсе, бу хурлыктан ничек кеше күзенә күреним", — дип әрләп ташлады.

"ЗА РУЛЕМ ЧТО ЛИ?"

Харис абый авылның алдынгы тракторчысы иде. Пенсия яшендә булса да, чылбырлы трактордан "беларусь"ка күчкәч, бераз сыйлангалап кайта башлады.

Бервакыт шулай, күршесенә утын китергәч, бераз төшергән килеш мәчеткә керә бу.

Мулла бабай Харис абыйдан "тәмле" ис сизеп:

— Син, Харис туган, эчкән килеш мәчеткә килмә инде! Болай йөрү ярамый бит! — ди.

Харис абый, үз чиратында, урысчалатып:

— Нишләп бераз гына ярамасын, трактор ведь оставил, за рулем что ли? — дип җаваплый.

"САБАН ТРАКТОРНЫ УЗГАН"

Элек, МТСлар заманында, күрше чуаш авылында Кәшиф абый чуаш дусты Илья белән җир сукалый икән.

Илья дәдәй, туган көне булганга күрә, төнгелеккә бер шешә самогон алып килә. Болар матур гына сыйлангач, Илья дәдәй:

— Кәшиф пичәй! Син мине узма инде, — ди.

— Юк, юк, Илья, сине узып буламы соң? Синең сабаның трактордан да тизрәк йөри бит, — дип, аны шатландырып, үзе шул арада тегенең сабанын ычкындырып куя.

Илья дәдәй кузгалып китеп бер әйләнеш ясый, артка карау юк. Чү, алда аның сабаны тора түгелме соң? Илья дәдәй хәмердән майланган күзләрен уып:

— Кара әле, малакайгынам! Кәшиф пичәй пелеп әйткән: сабан тракторны да узып киткән пит, — дип аптырап бот чапкан.

ШАЯН ХӘЛЛӘР

Элегрәк заманнарда авыл җирләрендә самогон кайнату белән шөгыльләнүчеләр бар иде. Заманасына карата авыр елларда халык рәхәтләнде инде.

Шулай да бу кырын эшне авыл советлары, участковыйлар тикшереп тордылар.

Авыл җирендә Хәбиб бу эштә берничә тапкыр тотылганга күрә, чираттагы самогонын әзерләгәч, үзе яшереп куеп, үзе участковый ролендә эзләп карарга була. Өч литрлы банкадагы самогонны мендәр астына яшерә дә, верандага чыгып үзе ишек шакый. Ике рольне бер үзе башкарып: "Кем бар анда?" — ди.

"Синдә самогон бар дип әйттеләр, бу авыл советы рәисе", — дип җавабын да бирә. "Әйдә кер, кара, тикшер!" Үзе карап йөри, тапмаганга сальпша, ә үзенең эчәсе килә бит. Йөри торгач, түзми, мендәр астыннан табып ала бит самогонны. "Әйдә, сыйланабыз", — дип, ике стаканга салып, үзен-үзе сыйлый. "Карале, малакайгынам, начар яшергәнмен", — дигән нәтиҗәгә килә дә, үз-үзенә сөйләнә-сөйләнә, самогон банкасын кабат су кисмәгенә яшерә. Тагын чыга да ишек шакый. "Кем анда?" "Бу мин — участковый". "Әле миндә яңа гына авыл советы булды, бер нәрсә дә тапмады", — дип үз-үзенә сорабын да, җавабын да таба бу.

Менә тагын керә дә, эзләргә тотына. "Әйттем бит, бер әйбер дә юк", — дигән була. Ә үзенең эчәсе килә. Ахырда түзми, су кисмәгеннән барып самогонны ала да: "Әйдә, салабыз", — дип участковый өчен дә, үзе өчен дә берәр стакан җибәрә. Бу хәл берничә тапкыр кабатлангач, исереп, идәнгә егыла. Шулвакыт ишек шакыйлар. "Без милициядән", — дигәнгә: "Сезнекеләр ике тапкыр килделәр, эчтеләр дә, калганын үзләре белән алып киттеләр, пошли вы отсюда, к черту вас", — дип канәгать калып, икенче якка борылган да яткан Хәбибулла.

“БОЛАЙ БУЛГАЧ ЯШИБЕЗ!”

Һәрвакыт салмыш йөргән, шуңа күрә бөтен тирә-күршене туйдырып бетергән Рәхимҗан бервакыт иртән Хәлимә апаларга килеп керә:

— Үтермә, Хәлимә апа! Берәр нәрсә салып бир!

Бу хәлләрдән туйган Хәлимә апа почмак яктан бер стакан салкын су алып чыгып:

— Мә, тыгын! Башка күземә күренәсе булма! — ди.

Рәхимҗан бер стакан салкын суны каплап куя да, әллә белеп, әллә белештермичә:

— Рәхмәтләр яусын, Хәлимә апа! Болай булгач яшибез! — дип чыгып китә.

“ПАСПОРТТА ТАТАР ДИЕЛГӘН”

Армия хезмәтенә юлда барганда Азнакай районы егетләре белән аралашып киттем. Сөйләмдә сүз төрләренең аерымлыгы булгач:

— Әллә син мишәрме? — дип кызыксындылар.

Армиягә кадәр читкә чыгып йөрмәгәч, "мишәр" сүзе таныш булмаганга күрә:

— Китегез әле, егетләр, юкны сөйләмәгез! Паспортта татар диелгән, — дип аңлаттым.

Икенче бүлек

ЭТ ЕЛЫНА КЕРГӘНДӘ ТЕЛӘКЛӘР

Киләчәккә өметләнеп,
Эт елына керәбез.
Үткәненнән дә начарны
Эт елында күрмәбез.

* * *

Эт елына шатлык өстәп,
Карлар да яуды инде.
Бәхет әле алда булыр,
Авырлыклар калды инде.

* * *

Эт елына кергән сәгатьтә
Бәхет телик бер-беребезгә.
Шатлыклар алып килсен иде
Эт дустыбыз һәр көнебезгә.

* * *

Эт елына ышанып керик
Шәймиев бабай булганда.
Илебездә тынычлык булса,
Бәхет булыр Татарстанда.

ЧИРМЕШӘНЕМ, ЧИРМЕШӘН!

Ринат Гобәйдуллин музыкасы



Кайтам эле Чирмешәнгә,
Суларын эчәм эле.
Онытмамын, дигәннәрнен
Исенә төшәм эле.

Кушымта:

Чирмешәнем, Чирмешән,
Җан яраткан төбәгем.
Кайчан күрешербез диеп,
Яна минем йөрәгем.

Сөлчә суын учка алып,
Битемне юам эле.
Күкрәгемдә туган якның
Рәхәтен тоям эле.

Кушымта:

Кайтып киләм Чирмешәнгә
Сабан туен күрергә,
Яшьлегем белән очрашып,
Дуслар белән йөрергә.



ТУГАН ЯК БИЗӘКЛӘРЕ

Читкә киткәч,ниләр генә
Күрми адәм башлары.
Истән чыкмый Иске Кади,
Ташъелганың ташлары.

Камал умарталыгында
Каен жиләге пешә.
Чишмә суларының тәме
Һаман исемә төшә.

Кыек юл озатып кала
Кади урманнарына:
Имән, юкә, ак каеннар
Үсә торганнарына.

Авылым артында гына
Чәчәкле болыннары.
Шул болында кызлар йөри,
Озындыр толымнары.

Анда калды мәхәббәтем —
Хыялларның татлысы.
Бакчамдагы чәчәкләрдә
Минем туган як төсе.

АВЫЛЫМНЫ САГЫНАМ

Авылым урамнары,
Яшелдер чирәмнәре.
Күңелем хатирәсен
Шигырьгә үрәм әле.

Мәктәп елларын һаман
Күңелем саклап тора.
Авылымны сагыну
Җәяүләп атлаттыра.

Авылдашлар басуда
Чәчәдер дә урадыр.
Кендек каным тамган җир
Мине көтеп торадыр.

Кайтам мин авылыма
Балачакны сагынып.
Кошлар китеп баралар
Тегәрҗепкә тагылып.

АВЫЛЫМ ИСКЕ КАДИ

Әхтәм Миңлебаев көе



Авылым урамнары,
Балачак чирәмнәре...
Яшьлегем хатирәсен
Гөлләргә үрәм әле.

Кушымта: Борынгы минем авылым,
Исеме Иске Кади.
Туган якта искән җил дә
Иркәләп чәчне тарый.
Сөлчә эрәмәләренә
Ямь бирен кошлар сайрый.

Мәктәп еллары истә,
Күңел түрендә тора.
Туган җирем сагышны
Шатлыкка алмаштыра.

Кушымта: Борынгы минем авылым,
Исеме Иске Кади.
Туган якта искән җил дә
Иркәләп чәчне тарый.
Гашыйк җаннар бер-берсенә
Сөеп, яратып карый.

Ерактан ук каршылап
Яңгырый изге азан,
Читтә гомер итсәм дә
Авылым көч бирә һаман.

Кушымта: Борынгы минем авылым,
Исеме Иске Кади.
Туган якта искән җил дә
Иркәләп чәчне тарый.
Кырларында икмәк исе,
Күгендә тургай сайрый.

Гашыйк җаннар бер-берсенә
Сөеп, яратып карый.
Кырларында икмәк исе,
Күгендә тургай сайрый,
Авылым Иске Кади.

ДУСЛАРГА

Урманнарга кошлар кирәк
Бөҗәкләрне ашарга.
Кешеләргә дуслар кирәк,
Ярдәмләшеп яшәргә.

Янда дусларың булмаса,
Бәйрәмнең дә яме юк.
Җанда тынычлык булмаса,
Ширбәтнең дә тәме юк.

Эх, дусларым, телим сезгә,
Бәхетле булыгыз, дип,
Озын булсын гомерегез,
Барасы юлыгыз, дип.

* * *

Зарланма, дус, азмы күрде диеп,
Башлар бу дөньяның газабын.
Безнең көрәшләр алда әле,
Үтәсе бер гомер азагын.

ЯШЬТӘШЛӘРГӘ, КЛАССТАШЛАРГА

Илле дүрткә соң ноктаны куеп
Илле бишкә аяк атладык.
Иске Кади, күп җирләрдә
Синнән дә матур җир тапмадык.

Илле дүрт яшь күп тә түгел кебек,
Аз да түгел — чәчләр көмешле.
Безнең язлар шау чәчәктә иде,
Көзләребез булсын җимешле.

Гомер җәйләребез үтеп бара,
Кошлар да сайрамый юатып.
Таң алдыннан җырлап үтик әле,
Авылны йокыдан уятып.

Яшьлектәге җырлар һаман истә,
Кайтыйк әле егет чакларга.
Бергә чаклар бик тиз үтеп китәр,
Таралырбыз төрле якларга.

Тагын күрешкәнче айлар үтәр,
Киткән кошлар кире кайтырлар.
Безне җилкендереп бакчаларда,
Гөлләр кабат чәчәк атырлар.

Гомер үтә, диеп кайгырмагыз,
Алда көзләр, кышлар бар әле.
Көз-кышларны бергә каршыларга
Янда сез — дуслар бар әле.

ЯКТАШЛАР ОЧРАШУЫ

Яңгырый җырлар сәхнәдә,
Алкышларга күмелә.
"Энергетик" сәхнәсендә
Нинди бәйрәм, кем белә?

Якташлар очрашуы бу,
Музыкаль утлар яна.
Гөлзада — алып баручы,
Теленнән гөлләр тама.

Ринат баянын сайрата,
Тансык гармун тавышы.
Искә төшә Чирмешәннең
Зифа буйлы камышы.

Мактауга лаеклыларга
Тапшыралар бүләкләр.
Гомер буе юлдаш булсын
Безнең изге теләкләр.

Күңелләргә шатлык тула,
Хисләр ургып ташыйлар.
Авылдашлар, якташларым
Мул тормышта яшиләр.

Якташлар очрашуыннан
Тәэсирләнеп кайтабыз.
Бәйрәм өчен Гөлзадага
Зур рәхмәтләр әйтәбез.

Өченче бүлек

ПАРЧАЛАР

НИЧЕК ТЕРЕЛМИСЕҢ ИНДЕ

Җитмеш ике яшьлек Фәһимә апабыз нык авырый, дип ишеткәч, авылга кайтып, аның хәлен белеп килергә булдык. Күчтәнәчкә тәмле чәйләр, төрле-төрле тәм-том һәм матур гына бер чәй сервизы алдык та киттек авылга. Болар безне җылы гына каршы алдылар. Фәһимә апа аякка басып әкрен генә йөри башлаган иде.

Менә чәй янына утырдык, күчтәнәчләрне дә, матур чәй сервизын да куйгач, өстәлебезгә ямь өстәлде. Хуҗаларның күңелләре күтәрелеп китте.

Апа белән Вагыйз җизнигә:

— Әйдәгез әле, шәһәр күчтәнәчләре белән, матур сервиздан һинд чәйләрен эчик әле, бәлки бераз шифасы да тиеп китәр, — дидем.

Фәһимә апам да сүзгә кушылып:

— Шифасы да тимичә калмас, Аллаһы боерган булса, нинди ерак арадан безне зурлап, искә алып кайткансыз, бу шатлыктан ничек терелмисең инде, — дип куйды.

Мондый җылы сүзләр безнең дә күңелне йомшартып җибәрде. Күрәм, җизнинең шатлыгы йөзенә чыккан, ә үзенең күзләреннән яшь тәгәри иде.

Менә ничек икән бу дөнья, бабай! Кайсы вакытта кешегә яхшы сүз дә дару, ә шатлыктан күңел нечкәрүләре үзе бер дәва була икән. Шуннан соң Фәһимә апабыз терелде.

ИКЕ МАЛАЙ СӨЙЛӘШӘ

Артур Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. Менә-менә кайтыр дип көтәбез. Икенчесе — Амур 13 июньдә китәргә тиеш, кулында повестка. Малайлар бер-берсе белән күрешә алмаслар инде, дип, үзем дә борчылам.

Менә бервакыт олы малай чылтырата. Ике брат телефоннан сөйләшәләр.

Артур:

— Брат, наверняка кайтып өлгереп булмас, моннан безнең якка билетлар юк. Ярар, күрешә алмасак, үпкәләмә инде, ике ел күп түгел, үтеп китәр әле ул гомер, — ди.

Амур:

— Ярар, брат, кайгырма, дөньялар тыныч, үзебез исән булыйк, киләчәктә күрешербез әле, — диде дә, телефон өзелде.

Ә мин күрше бүлмәдән ике малайның сөйләшкәнен тыңлап тордым. Күңел сыкрый, күздән яшь тәгәри, малайларны күрештерәсе килә, ну, нишлисең, ара ерак, язмыш шулайдыр инде.

Ә шулай да, ике малай сөйләшкәч, миндәге шатлык яшьләре күңелемне тынычландырып, тәнгә сихәт бирде.



Үзем турында да яшь чактагы бер кызыклы вакыйганы язарга булдым.

“КАЗЫҢ ДА КИРӘКМИ, ҮЗЕҢ ДӘ КИРӘКМИ”

1970 нче елның 22 октябре, кулымда 8 ноябрьгә армиягә китәргә повестка. Унынчы сыйныфны бетергәч, армиягә киткәнче тракторны иярләдем.

Хәзер дә хәтерлим: 22 октябрь шундый кояшлы җылы көн иде. Без биш трактор белән күрше Киязлы авылы белән Якты Тау арасындагы кырны сукаладык.

Бервакытны карасам, минем яшьтәшләр Юныс, Минсалих (алар прицепщик булып йөриләр иде) бераз күңелләнеп алганнар. Мин әйтәм:

— Кем сыйлады? Каян алдыгыз зәм-зәм суын? — дим. Алар, күрше чуаш Киязлысына салам илтеп, сыйланып кайтканнар икән. Болар кәефле, үзләре кайда-ничек сыйланганнарын әйтмиләр.

— Без булган җирдә сиңа анда тәтеми, — диләр. Минем ачу килде бит. Егет чак, болардан уздырасы килә. Җитмәсә, Юныс белән бер көнне армиягә китәргә дә.

— Көтеп торыгыз! Бер сәгатьтән кайтып җитәм. Әгәр дә сезне сыйларга бернәрсә дә алып кайтмасам, исемем — Фәнис булмасын, — дим.

Үзем тракторның тизлеген арттырдым, иңкү (чокырлы) урында төшкәч, тегеләр күрмәсен, дип кырдан бер казны тотып алдым да, аргамакны прицепщик Әбүзәрләргә калдырып, киттем авылга. Култык астында капчыкта каз бар, бер җае табылыр әле, дим.

Карыйм: капка төбендә бер чуаш хатыны басып тора. Безнең заманда чуаш халкы татарчаны яхшы сукалый иде. Мин бу апага җайлап кына повестканы күрсәттем:

— Әни кырга эшкә киткәндә бер каз бирде дә, армиягә китәр алдыннан истәлек булып калсын, рәхәтләнеп ашагыз, дигән иде.

Повестканы да күргәч, бу апам ышанды бит, казны өч литр

самогонга алыштырдым. Чуаш авылына култык астына каз кыстырып килсәм, кайтканда кулыма алтын кош тоткандай кайттым, янәсе, малайларның борыннарына чирттерәм. Шулай итеп, без әйбәт кенә сыйландык. Бригадир Хөснулла абыйны да, урамдаш дустым Исмәгыйльне дә сыйладым.

Менә 6 ноябрь килеп җитте, миңа 8 ендә армиягә бит инде. Безнең Иске Кади авылы үзешчәннәре Якты Тауга (поселокка) концерт белән бардылар. Мин дә, Исмәгыйльне ияртеп, дуслар белән саубуллашырга киттем.

Ни дигәндә, егет вакыт, дуслар белән сыйландык та, бер-беребезгә җылы сүзләр әйтеп, хушлаштык. Шулай да безне нәрсәдер котырта бит, нидер җитми.

Киттек Якты Таудан өч-дүрт чакрым ераклыктагы чуаш Киязлысына. Аякта туфли, кар керә, ул вакытта кар төште дә, аннан соң яңадан эреде.

Шулай итеп барып җиттек. Тәрәзә шакыйм Настя апага.

— Кем бар анда? — ди чуаш акценты белән Настя апа.

— Бу мин, каз китергән малай. Менә, армиягә алмадылар, Аксубайдан кайтып килеш, җылынып чыгарга гына керт әле, — дим.

Беләм: кертсә, кесәдә акча бар, бер ярты алабыз да ычкынабыз инде. Ну без уйлаганча булып чыкмады. Настя түтәй бермәлне чәрелдәп:

— Чукынып та йөрмә! Казың да кирәкми, үзең дә кирәкми. Казың күрше казы булган, икенче көнне ук алып чыгып киттеләр, — диде. Кызу-кызу чуаш акценты белән сүкте дә, утың да сүндерде. Мондый көтелмәгән хәлдән һәм тиз-тиз әйтелгән такмак сүзләрдән соң безгә кызык та, мәзәк тә булып китте. Әле бит кирегә безнең тагы сигез чакрым тәпилисе бар иде.

Шулай да, бу вакыйга китәр алдыннан бер яшьлек сәхифәсе булып, күңелдә урнашып калган иде.

РӘХМӘТЕБЕЗ ЗУР

Әниемне юбилее белән котлап

Безнең әниебез Нуретдинова Мәймүнә Хәниф кызына быел, ягъни 2006 елның 20 нче мартында, 75 яшь тулды. Шул уңайдан әниебез хөрмәтенә бер истәлек калдырасы иттем.

Әле хәзер дә исемдә, 1963—64 елларда хезмәт көненә икмәк бик аз тиде. Әтиебез сугыш ветераны, группадагы инвалид, авыл советында салым агенты булып эшли иде. Аңа, бюджет системасында эшләгән кешегә, колхоздан икмәк бирелми торган замана. Әнинең генә хезмәт көненә тигән икмәк безне туйдырырлык түгел, гаиләбез шактый ишле: без дүрт малай — иң кечебезгә өч яшь, тагын пенсиядәге әби белән бабай бар. Барыбыз бер әнигә карап торабыз. Ул инде, башка чара тапмагангадыр, леспромхозга урман кисәргә йөри башлады. Ир-атлар өчен дә авыр хезмәт бит ул агач эше. Ләкин әни канәгать, аннан да битәр без шат, чөнки тамак тук — өйгә көн дә леспромхоз пекарнясыннан яңа пешкән ипи кайта.

Әтиебез иртә китте. Әни 44 яшендә тол калды. Ул безнең бердәнбер терәгебез иде. Иң авыр елларда да бирешмәде, сыкранмады, көчен кызганмады. Инде барыбыз да аякка баскач, 50 яшен тутырган әниебез безнең янга — Чаллы каласына килде. Двигательләр заводында идән юучы булып эшләп, бер бүлмә алды. Һәрвакыт алдынгылар рәтендә булган әниебезне зурлап лаеклы ялга озаттылар, бер бүлмәле фатир да бирделәр.

Әни — безнең иң беренче киңәшчебез. Хәзер дә барыбызны да барлап, хәлебезне белешеп тора. Ак яулыгын бәйләп, догасын кылып, хәер-фатихасын бирә. Ана өчен бала, үзе әти яки әни булса да, барыбер бала. Менә без үзебез — әтиләр, хәтта яннарыбызда оныкларыбыз да йөгереп йөри — шушы самими балалык хисләрен яңадан тоемлар өчен, әни янына киләбез. Әниебез янында, вакытлы гына булса да, үзебезне бала итеп хис итеп утырабыз. Безгә мондый бәхетле мизгелләрне тату әле тагын озак-озак еллар насыйп булсын иде.

Кадерле, газиз әниебезнең сау-сәламәт булып, бәрәкәтле озын гомер кичерүен телибез. Ул булмаса, тормышыбызның ямe дә, тәме дә булмас иде.

Аллаһының мең рәхмәте яусын аңа. Күңелендәге җан җылысының нуры сүнмичә, сүрелмичә без — балаларына яшәеш чыганагы булып торсын.

КЫЯМ БАБАМ ИСТӘЛЕГЕ

70 елның 8 ноябрендә армиягә киттем мин. Табын әзерләп туган-тумача, күрше-күләнне җыеп озату кичәсе уздырдык. Чигүле кульяулыклар, җырлашу-елашулар — барысы да булды. Озатучылардан Кыям бабам хәтеремә бик тирән уелып калган. 85 ен тутырган, моңарчы беркайчан да күзендә яшь күрсәтмәгән бабакай минем белән саубуллашканда: "Күрешә алмасак, хуш, бәхил бул", — диде дә елап җибәрде. Мин, егет кеше, үземне горур тотып, шактый коры гына саубуллаштым.

Район мәдәният йортында мактау грамоталары тапшырып, Казанга, аннан, хәрби эшелонга төяп, көнчыгышка озаттылар.

Вагонда миңа өченче яруска урнашырга туры килде. Поезд барган көйгә уйланып ятам шулай, соңгы бер-ике көндә булган кичерешләр тәэсирендә. Бөтен вакыйгаларны күз алдымнан уздырам. Шулчак бабамның әйткән сүзләре, яшьле күзләре исемә төште, күңелем тулып, тыела алмыйча елап ук җибәрдем. Тамак төбенә төерләнгән хисләрем, кичерешләрем кайнар яшь бөртекләренә әверелеп тәгәрәшәләр иде. Ничек капка төбендә еламадым икән соң мин? Егетлек күрсәтү булдымы икән ул?

Хушлашканда бабамның күңеле сизгәндер, күрәсең, безгә аның белән кабат күрешү насыйп булмады. Бер ел хезмәт иткәч, аның вафат булуы турында телеграмма алдым. Әмма соңгы юлга озатырга кайта алмадым. Әтием, Бөек Ватан сугышы ветераны, үзенең авырып киткәнлеген хәбәр итеп, мине кайтартырга тырышып караган иде каравын. Ләкин телеграмманы табиб расламаган булгач, хәрби комиссариатка, аннан районга кире хәбәр җибәрәләр. Әтинең хәлен белергә дип районнан шалтыратучыга колхоз идарәсеннән хисапчы кызның "эшләп йөри әле", дигән туры җавабы килеп ирешә. Шулай итеп, миңа авылга бабамны җирләргә кайту насыйп булмый калды.

Бабам бик туры, чиста күңелле кеше иде. Мин аны әле дә сагынып искә алам. Капка төбендә озатып калганда әйткән сүзләре һаман да колагымда яңгырый кебек.

ҖЫРЧЫ КЫЗЧЫК

Күрше-тирәдә яшәүче абый-апалар өч яшьлек Миләүшәне урамда очраткан саен җырлаталар. Җырлата дигәч тә, Миләүшәнең төрле чагы була: теләсә җырлый, теләмәсә — юк. Бер киреләнсә, ансат кына игә китереп булмый аны.

Менә әле беркөн генә чатта яшәүче Ахун бабай Миләүшәләр турыннан узып барышлый туктап: "Кызым, әйдә, бер җырла әле", — дип йомшак кына итеп сүз катып караган иде дә, кызчыкның нигәдер бик исе китмәде. "Әйм", — диде дә, үзе читкәрәк китеп бабайга карап тора башлады. Ахунҗан бабасы аны берәр нәрсә өмет итә дип белеп ахрысы, кесәләрен капшаштырды. Тик конфет-прәннек ише әйбер салып чыкмаган икән шул, ике тиенлек бакыр акча гына табылды кесә төбеннән. Бабай акчаны кызчыкның нәни учына салды. Миләүшә учын ачып карады да, акчаны йодрыгына кысып, йөгереп өйләренә кереп китте.

Акчасын әнисенә күрсәтеп, сөенечен уртаклашты Миләүшә. Әнисе генә аптырады: "Бабайның акчасын алгансың, нигә соң җырламадың?" — диде. Чынлап та, нигә киреләнде икән соң ул? Акчаны бушка гына алып калган бит инде болай булгач. Әнә шулай уйлап борчылды, кич яткач та йоклап китә алмыйча боргаланды Миләүшә.

Иртән торгач ук, кибет ачылган сәгатьне көтеп алган апасына ияреп, кибеткә китте. Барышлый Ахун бабайлар өе турысыннан узасы бар иде, узып китә алмады Миләүшә. Апасын гаҗәпкә калдырып, йөгереп капкаларыннан кереп китте.

Бабай өйдә күренмәде, килене Хәтимә апа белән оныгы Рәшит чәйләп утыралар иде. Сулышы кабып кергән кызчыкка аның әйтеп тә өлгерә алмадылар.

Иртә буран, кич тә буран
Мамык шәлеңне уран.
Кигән киемеңне күрсәм дә,
Җаныем-бәгырем,

Үзең күргәндәй булам, — дип үзе белгәнчә җырлап бирде дә Миләүшә, ничек кергән булса, шулай ук йөгереп чыгып та китте. Кызчыкның тизрәк апасын куып җитәсе бар. Кибеткә барып Ахунҗан бабасы биргән теге ике тиенне курыкмыйча "туздыра" ала бит ул хәзер, намусы чистарды.

Хәтимә апасы исә чынлап та аптыраашта калган булган икән. Шул ук көнне Миләүшәнең әнисе очрагач:

— Кызыңа нәрсә булган, йөгереп кердә дә тиз-тиз җырлап чыгып йөгерде, — дип сораштырып торган. Хәлнең асылын төшендереп биргәннән соң гына икесе дә тынычланып көлешкәннәр.

Боларын Миләүшәгә әнисе соңыннан сөйләде.

МИЛӘҮШӘНЕҢ МӘШӘКАТЬЛӘРЕ

Миләүшә — гаиләдә төпчек кыз. Өч апасы бар аның: Хәтимә, Әлфия, Нәсимә. Хәтимә апасы зур инде, мәктәпне бетерде дә сыер савучы булып эшли башлады. Әлфия белән Нәсимә апасы мәктәптә укыйлар әле, хәзер алар җәйге ялда. Ә олы апасы җәйләүгә йөри. Их, Миләүшә дә көн саен барыр иде ул җәйләүгә. Сыер савучы апаларның эшләгәннәрен карап торуы бик күңелле. Миләүшәнең килгәнен яраталар ул апалар. Зур үскәч Миләүшә дә сыер савучы булыр, җәйләрен җәйләүгә чыгып эшләр әле.

Тик әлегә сирәк эләгә аңа мондый бәхет. Әнә бүген дә әтиләре олы апасына төшке аш илтергә кушты. Зуррак кыз булганга инде, Әлфия апасы барачак анда. Миләүшәнең ничек тә булса апасына иярәсе килә иде, җаен гына тапмый аптырады. Чөнки, бердән, аңа үзләреннән берничә йорт арырак яшәүче әтисе белән бертуган Вәсимә апаларына кучтәнәч кертергә куштылар. Ә Әлфия апасы аны көтеп тормаса? Икенчедән, аны ияртергә бик ашкынып торучы да юк әле.

Уйлады, уйлады да, кече апасын ярдәмгә чакырырга булды. Әмма Нәсимә апасы да аның хәленә керергә бер дә атлыгып тормый шул. Олы апасы бүләк иткән бик матур брошкасын бирәм дигәч кенә, ниһаять, Миләүшәнең йомышын үтәргә ризалыгын бирде. Брошка кадерле иде кадерлесен, төрле төсләргә кереп җемелдәп аның кашлары. Тик җәйләүгә барасы килү теләге бар нәрсәдән дә көчле иде.

Кече апасы белән килешеп бетте дә урамга йөгереп чыкты Миләүшә. Әлфия апасы капка төбендә юк иде инде, көтмәгән, димәк. Күрсәнә, тыкрыктан борылып маташа түгелме инде. Бар көченә тыкрыкка таба йөгерде кыз. Инде куып җитәм, дигәндә, Әлфия апасы чүт кенә машинага утырып китми калды. Ярый әле, машина йөртүче Рәхимҗан абый Миләүшәне абайлап өлгерде, көтеп алды да кабинасына күтәреп үк утыртты. Кызның башы күккә тиде. Апасына үпкәлисе килгәне дә, брошкасыз калу кайгысы да онытылды. Җәйләүгә бару шатлыгы аның бөтен барлыгын биләп алган иде бу мәлдә.

“АРМИЯГӘ БАРЫШЛЫЙ МИШӘРЛЕГЕМНЕ БЕЛДЕМ”

Авылдан чыгып киткәнгә дә 35 ел тулып узды. Бүген Чаллының “Энергетик” мәдәният сараенда Азнакай районының якташлар очрашуы кичәсе бара. Якташлар очрашуы турында бер-ике сүз әйтеп китим инде, гаеп итмәссез.

Үзем Чирмешән якташлар җәмгыяте рәисе буларак, якташлар очрашуына һәрдаим йөреп торам. Бу очрашуларны “Энергетик” мәдәният сарае директоры, атказанган мәдәният хезмәткәре, Чаллы шәһәренең “Левитан”ы Гөлзадә Мөхәммәт кызы Рзаева алып бара. Аның тавышында ниндидер бер үзенчәлекле тарту көче һәм дә кешегә энергия бирә торган бер аһәң бар дип әйтер идем. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел, чөнки ул оештырган кичәләрдән мин үземә ниндидер көч һәм рухи байлык алып китәм.

Кыскасы, мин азнакайлылар арасында, армия хезмәтендә Азнакай егетләре белән бергә булганга күрә, шул хатирәләрне барлап утырам. Әле хәзер дә исемдә: 1970 нче елның 11 нче ноябрендә безне — Казаннан 21 егетне хәрби эшелонга төяп, Ерак Көнчыгышка таба алып киттеләр. Юлда барганда Азнакай районы егетләре Риф Сәетов (Зур Сухояштан), Фәнис Абдуллин (Мәсәгуттән), Альянс Заһидуллин (Тымытыктан) белән дуслашып киттем. Баштан бер-беребездән көлешеп бардык. Аларга безнең эпәй күгән (ипи көйгән), пүсш (почмак), имән әкәләсе (чикләвеге) һәм башка сүзләр ничектер кызык булып тоелдылар.

Мин дә аларның кайсыбер сүзләренә баштарак ияләшеп җитә алмадым. Ничек инде ашны да эч, чәйне дә эч, аракы да эч, бу эчүгә кубенергә була, дип шаярта торган идек. Менә шулай көлешә-көлешә унбер тәүлек дигәндә, без Хабаровскига килеп җиттек. Юлда шулай шаярышып башланган дуслык, хезмәт иткәндә чын дуслыкка әверелеп, бер вакытта да бер-беребезне кыерсыттырмадык.

Менә хәзер дә бу дуслыкны искә төшереп, Азнакай районы халкының якташлар очрашуы кичәсенә бердәм килеп, үзләренең дустанә мөнәсәбәтләрен якынайтуларына шатланып утырам. Утызбиш ел гомер узса да дуслык онытылмый икән. Бу язмам киләчәктә Азнакай дусларга мәдхия булып, бер истәлек булсын иде.

ЭЧТӘЛЕК

Елмаешып теләк теләшик 3
Кереш сүз 4

Беренче бүлек

"Аяклар йоклый алмый" 5
"Тагын бер әйләник әле" 5
"Тагын пешер әле" 5
"Подругасы мыеклы иде" 6
"Сатып алган бишлең түгел" 6
"Ул рогатка түгел бит" 6
"Аягың белән язсаң да" 6
"Урысчасы “чәнчүшкә” 7
"Ахбах була ул" 7
“Яткан Җирендә ят та ят!” 7
Пиво шикелле 7
“Җиви хорошо” 8
“Сине аннан атармын” 8
"Менә шул була" 8
"Гитлер татар булган..." 9
"Тракторда ашамыйлар" 9
"Чуртым булса да, кайнар булсын" 9
"Жить или не жить" 10
"Свежий түгел икәнсең" 10
"Син моржадан, мин тәрәзәдән" 10
"Сандугач балалары шикелле" 11
"Кайсы дуңгызы кабызган?" 11
"Бераз юарга кирәк" 11
"Эпәй белән генә ашыйм" 12
"Дистага күчте" 12
"Әллә чынлап буаз булганмы?" 12
"Бөртек" 13
"Рәсәйдә кәҗә савып" 13
"Пиво булса, эчәр идем" 13
"Бер пар рукавица" 14
“Чебурашка” 14
“Ну апаткан шикәрне” 14
"Кәгазе бик матур" 15
"Моннан да искесе бармы?" 15
"Менә сиңа кукиш" 15
"Зур күл була" 16
"Бирермен мин сиңа братыңны" 16
"Син бит сарык түгелсең" 16

"Сытын кына күрсәтермен" 16
"Иш куышында ышыкланып тордым" 17
"Ирлегемне итәм, барыбер чыкмыйм!" 17
"Сазлы булса да ярый" 17
"Ефәк бит ул" 18
"Аякка кирәк иде" 18
"Теләсә ничек аңла" 18
"Идән астыннан сөйләп тора торгандыр" 19
"Ничек туйдырырсың?" 19
"Казан сөйли" 19
"Кайчан әйтерләр" 19
"Безнеке яңарак" 20
"Сабыйлыгым белән генә йөрим" 20
"Сәламләшү" 20
"Рәшит капчыклары" 20
"Үземдә дә утыз сутый" 21
"Ялгыз калдым" 21
"Трамвай машина түгел" 21
"Иди сюда, галош" 21
"Низам белән Нәҗми" 22
"Безгә дә ярар" 22
"Йоны да юк әле" 22
"Аклыкка ак" 23
"Вы живы что ли?" 23
"Үзеңнекен бел!" 23
"Мин дә пешгем бит" 24
"Хәйләкәр алым" 24
"Бер үк җиңелде дип уйлама" 24
"Яшисең инде үлгәнчегә кадәр" 25
"Ишкәнсең ишәк чумарын" 25
"Сиңа килә иде бит" 25
"Фамилиясе туры килмәде" 26
"Наен, наен" 26
"Туган як исләре" 26
"Аны суктыра калдылар әле" 27
"Сине үртәмиләр бит!" 27
"Ешрак бирергә кирәк" 28
"Чип-чиста писуктан" 28
"Тәкә кычкыра башлады" 28
"Кутыр чыгарып булмый" 29
"Песи-карак" 29
"Алып кит петкән бозавынны" 30
"Шифонер артыннан чыкканнары да юк" 30
"Лучше в магазине куплю" 30
"Урамда ишеткәннәрдән" 31
"Килениән баш-аяк" 31

"Дусларың да туйганнар" 31
"Әйбәт булган бәкәй" 32
"Үземнекен ишәм бит" 32
"Дүрт аяклап йогырта" 32
"Токмачтан котылганнар" 32
"Зато югалмый" 33
"Миңа салма. Мин эчмим" 33
"Зәм-зәм суы" 33
"Һау-Һау" 34
"Үзем эшләп алган" 34
"Шуның белән петте!" 34
"Бөтенләй рәхәткә чумдым" 35
"Баш беткән иде" 35
"Спиртное не пью" 36
"Настоящий аракы" 36
"Синең сасыган самогоныңа..." 37
"Хатын гына янына яткырмый" 37
"За рулем что ли?" 38
"Сабан тракторны узган" 38
Шаян хәлләр 39
"Болай булгач яшибез!" 40
"Паспортта татар диелгән" 40

Икенче бүлек

Эт елына кергәндә теләкләр 41
Чирмешәнем, Чирмешән! 42
Туган як бизәкләре 44
Авылымны сагынам 45
Авылым Иске Калн 46
Дусларга 48
Яшьтәшләргә, классташларга 49
Якташлар очрашуы 50

Өченче бүлек

Парчалар 51
Ничек терелмисең инде 51
Ике малай сөйләшә 52
"Казың да кирәкми, үзең дә кирәкми" 53
Рәхмәтебез зур 55
Кыям бабам истәлеге 56
Җырчы кызчык 57
Миләүшәнең мәшәкатьләре 59
"Армиягә барышлый минәрлегемне белдем" 60
Эчтәлек 61

Литературно-художественное издание

Нуретдинов Фанис Бариевич

ЮМОР

(на татарском языке)

Мөхәррир — *Рәшит БӘШӘР*

Тышлык рәссамы — *Гөлнара САФИНА*

Корректор — *Ризидә КАМАЛОВА*

Компьютерда җыючы һәм биз әүче — *Резидә ТАИРОВА*

Җыярга тапшырылды 01.04.06. Компьютерда җыелды.
Формат 60x84 1/16. Тиражы 2000 данә.